**Мөхетдинова Рәмзия**

# *…Гомер мизгелләре бүләк итәм...*

**2016 ел.**

Китапны нәшер итүдә бар чыгымнарны күтәрүче –Рифнур Хаҗинур улы Таҗиев. Ихлас күңелемнән аңа олы рәхмәтемне белдерәм.



Рәфиснур Фәйзерахман улы Закировка зур ярдәме өчен шулай ук олы рәхмәт сүзләрен җиткерәм.

Афәрин, Бәзәкә егетләре! Ходай Тәгалә үзегезне шулай бүләкләсен!



**Безнекеләрне бел!**

# Күңелдә йөрткән уй-теләк.



Мәктәптә укыткан елларымда хисапсыз сыйныф сәгатьләрендә, кичә-очрашуларда укучыларга һөнәр сайлау турында әңгәмә-сөйләшүләр, фикер алышулар уздыра, һәр һөнәрнең уңай яки тискәре якларын ачыклый идек. Балалар укытучы, авыл хуҗалыгы белгече, табиб, төзүче һөнәрләре белән күбрәк кызыксыналар иде. Бу һөнәр ияләре турында әңгәмә корганда, һәрчак үз төбәгебездән чыккан, танылган, хөрмәт казанган авылдашларыбыз турында горурланып сөйли идек. Үзем алар турында язылган газета-журнал материалларын даими җыеп бардым. Менә шул елларда ук минем күңелемдә мактаулы якташларыбыз турында ни дә булса язасы килү теләге уянган иде. Байтак гомер узса да, күңелдә йөрткән шушы уй-теләгемне менә хәзер генә тормышка ашырырга булдым. Моңа уңай этәргеч биргән форсат та чыгып куйды. Авылдашыбыз Рифкать Минһаҗ улы Таҗиевның кеше сәламәтлеген, гомерен саклау өчен көрәш вахтасына басуына быел август аенда нәкъ 50 ел тула! Бу гаҗәеп врач-хирург турында газета-журналларда мәкаләләр бик күп басылды. Әмма гәҗит гәҗит булып кала. Ул күләмле дә, юка да, саргая-таушала, тиз ертыла. Аны дус-ишләргә бүләк тә итеп булмый. Ә китап бөтенләй башка нәрсә. Анда бар мәгълүмат бергә туплана, кеше язмышы-тормышы һәрчак синең кулыңда, синең күз алдында, аны кабат-кабат укыйсың, үзең белән ерак юлга аласың, якыннарыңа бүләк итәсең.

Шулай итеп, син кулыңа тоткан китап, дөнья күрде.

Атаклы табибның фидакарь хезмәте һәм тормыш девизы булган үз сүзләрен китапка исем итеп алдым.

# Сүзем – табиб турында.



Табиб профессиясе – җирдә иң гуманлы, иң кирәкле һөнәрләрнең берсе. Кеше табиб каршына иң зур байлыгы – сәламәтлеге какшагач килә. Ул врачтан

киңәш, ярдәм көтә һәм савыгу өмет итә. Кеше гомерен кайчак минутлар хәл итә. Табиб кешене үлем тырнагыннан тартып ала, аңа тормыш бүләк итә. Чын табиб якты йөзе, җылы сүзе белән, өмет тулы күзләрен тутырып, үзенә карап торган авыруның хәленә керә белә, авыр газапларын җиңеләйтергә алына, күңелендә яшәүгә, савыгуга ышаныч, юаныч тудыра...

Менә шундый табибларның берсе – Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы, профессор, озак еллар онкология һәм хирургия кафедрасын җитәкләгән, 114 фәнни эш авторы, медицина фәннәре докторы, Петровский Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Татарстан республикасы врачларының 2013 нче елгы “Ак чәчәкләр” һөнәри бәйгесенең җиңүчесе, “Ватан медицинасы өлкәсендәге һөнәри казанышлары өчен” дигән алтын медаль иясе, Менделеевск каласы һәм Бәзәкә авылының “Шәрәфле (почетлы) кешесе” дигән күкрәк билгесе иясе – врач-хирург Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев.

Үтә авыр, җаваплы, тынгысыз, эзләнүле, кыюлык һәм тәвәккәллек сорый торган хезмәтен бәяләп бирелгән бу кадәр олы исемнәр, зур дәрәҗәләр алган табибның тормыш-язмышының чишмә башы кайларда икән? Акрын гына атлый-атлый, хәтер–хатирәләрне яңартып, китап героебызның гомер сукмакларыннан үтик әле, балачагына, үткәннәренә күз салыйк...

## Туган авыл.




Чулман-Кама елгасының уң ярында урнашкан бик борынгы, таза-төзек, ямьле табигатьле матур бер авыл бар. Бу авыл Бондюг-Менделеев төбәгендә иң зур авыл – Бәзәкә авылы. Ул – безнең туып-үскән бишегебез.

Авылның көньягында, Кама елгасына кадәр (ул бездән 6-8 км тирәсе ераклыкта иде), дистәләгән чакрымнарга сузылган бөрлегәнле-карлыганлы, гөлҗимешле-баланлы әрәмәлекләр, җиләкле-чәчәкле, хуш исле печәнле болыннар җәйрәп ята. Җанга-тәнгә рәхәтлек бирүче, балыклы-төнбоеклы Пинәрә күле үзе ни тора! (Бу сихри гүзәллек безнең балачагыбыз һәм яшьлегебез чорында, Кама елгасын буып, бар матурлыклар, чиксез табигать байлыклары су астында калганчы иде).

Менә шундый гүзәл табигатьле авылда туып-үскән, урта мәктәпне бик яхшы тәмамлаган, зур тормышка юллама алып, табиб булу хыялы белән институтка кергән, матди һәм тел белән бәйле кыенлык-авырлыкларны җиңеп, бары алга – максатына омтылган, сайлаган һөнәренә тугры калып, кеше гомерен саклап калу өчен бар көчен, сәләтен, акыл эшчәнлеген, җыйнап кына әйткәндә – 50 ел гомерен игелекле, шәфкатьле хезмәткә багышлаган, республикабыз һәм туган авылыбызны данлаган гаҗәеп шәхес – табиб Рифкать Таҗиевны һәм башка бик күп танылган шәхесләр, галимнәр, атказанган кешеләр биргән авыл ул Бәзәкә.



# Өлкән Таҗиевлар.

Без Рифкать абый белән Бәзәкәдә, нәкъ бер очта, бер урамда, каракаршы йортларда туып үстек . Ул миннән өч яшь ярымга зуррак. Мин беренче сыйныфка укырга кергәндә, ул инде дүртенчене бетергән иде. Ә энесе Камил белән (инде мәрхүм, урыны җәннәттә булсын) без бер класста укыдык.



Әти-әниләребез дус-тату, бер-берсенә ярдәмле дә, киңәшле дә күршеләр булып яшәделәр. Минем әни дә, алар да гади колхозчы иделәр.

Минһаҗетдин ага 1901 елда ярлы крестьян гаиләсендә туган. 1920 нче елда армиягә алына. Гражданнар сугышында катнаша, көнбатыш фронтта ак полякларга каршы көрәшеп, Могилев – Минск – Брест-Литовск юлларын үтә, аягы бик җитди яралана.

Бөек Ватан сугышы башлануга Минһаҗ ага үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Әмма бу соңгы яуда ул инде катнаша алмый, төзәлмәс җәрәхәт моңа комачаулык итә. Сугышка ике энесе Фәттахетдин белән Фәссахетдинне һәм олы улы Зиннурны озаталар. Кирәк бит, Зиннурлар дивизиясе, нәкъ әтисе 20 нче елларда сугышып

үткән урыннарны, поляк, болгар, чех шәһәрләрен һәм авылларын фашист коллыгыннан азат итәләр. Зиннур Таҗиев сугышны Германиядә төгәлли. Фәттах абзый да сугыштан исән-имин әйләнеп кайта. Соңгы сулышына кадәр тәнендә снаряд ярчыгы йөртсә дә, 8 балага гомер биргән бу ир, бик күркәм гаилә башлыгы булып гомер кичерә. Ә энеләре Фәссахетдингә туган якларга кайту насыйп булмый. Яшь хатынын, үсмер улы Рафаилны, кече кызы Гөлфияне ятим итеп, чит җирләрдә мәңгелеккә ятып кала ул.



Авылда ир-егетләр юк диярлек, шунлыктан Минһаҗ аганы колхоз рәисе итеп куялар. Җигүле ат белән ул көне-төне басу-кырларда йөри, ындыр табагында, фермаларда була.



Әнисе Рәхимә апа бик тыныч, ипле, нечкә күңелле, бала җанлы хатын иде. Тулырак гәүдәле, түгәрәк йөзле, бик ачык кеше булып исемдә калган ул минем. Гаиләләре ишле. Өлкән балалары, берсе артыннан берсе үсеп җитеп, үз тормышларын корсалар да, ана кеше алар турында гел кайгыртып, алар һәм үзләре янында калган 3 улы өчен җан атып яши. Ул хуҗалыкны барлап тота, гаилә учагын сүндерми. Килен булып төшкән елларда җир җимертеп эшләп йөргән хатын соңга таба колхоз эшендә гел катнаша да алмый. Ачлык елларында бер-бер артлы 4 газиз баласын югалту хәсрәте ана кешенең йөрәген өзгәли, сәламәтлеген какшата. Озакламый үзе дә 53 яшендә гүр иясе була.

Икенче әниләре Шәмсекамал апа да уңган-булган, сабыр, кайгыртучан әни була ятим калган балаларга. Аңа ияреп килгән кызы Әнисәне дә яңа гаилә бик тиз үз итә, якын күрә. Кыз да, малайлар белән уртак тел табып, дус, тату мөнәсәбәттә була.



Минһаҗ абый, озын гомерле булып, 83 яшендә вафат булды. Әтисен карарга, тәрбияләргә Рифкать абый Казаннан атна саен кайтып йөрде. Соңгы вакытта Шәмсекамал апаны, Алабуга каласына алып китеп, кызы Әнисә тәрбияләде. Ул тагы да озаграк яшәп, 100 яше туларга 5 ай калгач вафат булды. Һәркайсының урыны җәннәттә булсын.

# Майда туган малай.

1943 ел, 1 нче май. Кояш баеп офыкка кереп бара. Зур капканы ачып, җигүле атта Минһаҗ ага эштән кайтып килә. (Әйдәгез әле, үзебезне спектакль карагандай хис итек һәм ир белән хатын арасындагы әңгәмәгә колак салыйк.)

- Анасы, мин кайттым. Әле йокларга ятмаган идеңме?

- Ай-һай, Минһаҗетдин, бигрәк озак йөрдең бүген.

- И-и, Рәхимәкәй, колхуз эшенең бетәсе бармы соң аның! Ир-егетләр бөтенләй юк бит, барысы сугышта. Бала-чага, хатын-кызлар белән генә әллә ни майтарып булмый шул.

- Анысы шулай инде. И-и, атасы, әллә күрмисең дә инде. Мин бит сиңа бүген бәби алып кайттым.

- Һай, җаныем, рәхмәт төшкере, әле бөтенләй күрми дә торам икән бит. Кемебез бар?

- Малай!

- Вәт, маладис, карчык, булдыргансың! Көн бик кояшлы, җылы булды бүген. Алла боерса, малай зу-у-р кеше булыр.

- Амин, шулай була күрсен. Чәчү беткәнне көтеп булмас бит инде, малайга исем кушасы булыр.

- Әйе,әйе, кушарбыз. Үзем кушам. Күр әле син, бөтен дөнья уяна, яшәрә, үләннәр баш калкыта, агачлар яфрак яра. Барысы да терелә, яшәргә тырыша, җирдә өр-яңа тормыш башлана, Рәхимәкәй.

- Әйе, атасы, яшәүдән дә ямьле тагын ни бар дөньяда! Әйдә, улыңны күрсәтәм.

# Исем кушу.

Сабыйга исем кушу өчен, мулла чакырып, аш мәҗлесе җыеп торыр чак түгел (азык-төлеккә дә кытлык чор бит). Минһаҗ ага, дин өлкәсендә белемле-гыйлемле кеше буларак, улына исем кушу йоласын үзе башкара.

- Сабый!
Исем кушабыз үзеңә.
Рәфкать атлы буласың.
Бәхет-тәүфиклар китерсен
Ата-бабаң йоласы.

Әтиең белән Әниең
Синнән изгелек күрсен.
Юлларында Хозыр Ильяс
Үзе озата йөрсен.

Май аенда тугач, улым,
Кояш кебек бул көләч.
Гомереӊ буе халкыңа
Бәхет-сәгадәт өләш.

Макталырсың, бәлки, үскәч,
Күчеп телдән-телләргә.
Ә хәзергә үс, тырыш бул,
Охшап язгы гөлләргә.

Бу шигъри юлларны мин юкка гына китермәдем. Ата белән ана, тупырдап торган матур, кара тутлы улларына нәкъ менә шундый сүзләр, уй-теләкләр белән аның гомер юлында бәхет-сәгадәт, сау-сәламәт булып, бары хәерле, игелекле гамәлләр генә насыйп булуын Аллаһы Тәгаләдән теләгәннәр, сораганнардыр.


РӘФКАТЬ – матур исем, мәгънәле исем (Ә без аны Рифкать дип йөртәбез). Бу исем безгә гарәпләрдән кергән. Ул “озата бару”, “юлдаш булу”, ягъни “гомер юлдашы” булу мәгънәсенә ия. Бу исемдә ир баланың әти-әнисе өчен гомер юлдашы булуы, тормышта кешеләргә ярдәмче, булышучы булуын күрү теләге чагылыш таба. Фарсы телендә бу исем “дан, данлы” дигәнне аңлата.

Малаеның нәкъ менә яз башында, бар табигать терелгән, җанланган мәлдә дөньяга килүе, сабыена кушкан исем киләчәктә аның тормыш-язмышына тәэсир итәр дип, юраганым юш килер дип, уйлады, белдеме икән ата кеше ул бәхетле көннәрдә?!

# Кабатланмас балачак.



Кечкенә Рифкать балалар бакчасына йөри. 1950нче елда 1нче сыйныфка укырга керә. Тәүге укытучысы Бөек Ватан сугышында катнашкан мөгаллимә Мәрьям апа Көләчева була. Рифкать мәктәптә тырыш, алдынгы укучы була. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша, спортны ярата. Мәктәп турында сүз башлагач, бер кызыклы табышка тап булуым турында әйтеп узыйм әле. Миңа аны укытучы Фирая апа Салихова күрсәткән иде. Ул укучысы Рифкать Таҗиевнең химия фәненнән эш дәфтәре иде. Укытучы ханым бу дәфтәрне (1958-1959 нчы уку елы өчен) үзендә 55 ел! саклаган. “Минем фәнемне бик яхшы белә иде Рифкать”,- дип, горурланып сөйләгән иде мөгаллимәбез. Бүгенге көндә Фирая апа вафат, урыны җәннәттә булсын.


ТЕТРАДЬ

для решения задач по химии

ученика класса

Бизякинской школы

Бондюжского р-на ТАССР

Тазеева Рифката

за 1958/59 уч. год

Ә кичләрен дус-иш малайлар, кызлар белән ярты төнгә кадәр качышлы, йөзек салыш, шәмәйле, буяучы һәм башка төрле уеннар уйныйлар. Холкы белән бик хәрәкәтчән, шаян Рифкать төрле шуклыклар, кызыклы хәлләр уйлап табарга оста иде. Менә шундый бер кызык хәл турында язарга булдым.

Мин икенчеме, өченчеме сыйныфта укыганмындыр. Җәйнең бер кичендә, күршеләребезнең ачык калган капкаларыннан, өйгә керә торган баскыч төбендә өч малайның бик тәмләп нәрсәдер ашап утыруларын үзебезнең тәрәзәдән күреп алдым. “Әһә, мин әйтәм, нәрсә ашыйлар икән болар?”. Дус кызым Мәүгыйдә бездә иде, аның белән кереп киттек боларга. Кузаклы яшел борчак ашыйлар икән. И-и, тәмләп,

безне кызыктырып, ымсындырып ашыйлар инде! Ә безгә бераз өлеш чыгару турында уйлап та карамыйлар. Авыз суларыбыз агып чыгардай булып торабыз басып.  Ниһаять, Рифкать абый сүз башлады:

- Нәрсә, ашыйсыгыз киләме?

- Әйе,- дип, баш кагабыз.

- Ә сез безгә нәрсә бирәсез?

- Безнең бер әйберебез дә юк.

- Ә-ә, алай булмый ул. Менә нәрсә эшлибез. Син, Рәмзия, өстеңдәге күлмәгеңне ерта аласыңмы? Ул чакта мин сиңа бер түбәтәй борчак бирәм.

Мин күлмәгемә карап куйдым. Кызыл җирлеккә вак кына ак чәчәкләр төшкән, түше бөреп-бөреп тегелгән бәби итәкле бик матур бумази күлмәк иде ул. Бик яратып кия идем үзен. Әмма борчак кузаклары да эреләр, бик тәмле күренәләр. Рифкать абый бер уч борчакны түбәтәенә салып та куйды. Мин тоттым да күлмәк итәгемне үземчә ертырга керештем. Тик бөкләп, калын итеп тегелгән бәби итәкнең җөйләрен ерта алмадым. Мәүгыйдә (нишләптер аңа күлмәк ертырга әйтмәделәр, ә-ә, аның абыйсы Габделхәй анда иде шул), җиңемнән тартып мине туктатмакчы да була, әмма мин инде, җиргә үк тезләнеп, итәкне тешләрем белән ертырга маташам, тик булдыра алмыйм. Шунда Рифкать абый келәтләреннән тиз генә кайчы алып килде, сарык йоны ала торган. Ләкин аның белән дә эш килеп чыкмады, ул минем кулларыма зур иде. Минем озак мыштырдавымны күреп, Рифкать абый өйләреннән бик үткен, әтисе кырына торган (“безопасный”дип атала иде бугай ул) пәке алып чыкты да, минем каршыма килеп басты. Борын төбемдә үк үткен пәке күргәч, гәүдәм калтырый башлады, күзләрем шардай булды. ”Я, күлмәгеңне киссәк, еламассыңмы?”. Мин, юк дигәнне белдереп, башымны чайкадым. “Алайса, йом күзеңне!” – дип, боерды Рифкать абый. Чытырдатып йомдым күзләремне. Ә ул, күлмәгемне ияк астыннан ук тотты да, өстән аска кадәр ярды да төшерде. Шытырдап икегә аерылып баручы күлмәгемне мин кулларым белән бөгәрләп тота бардым. Рифкать абый: “Мә, борчагыңны”,- диде дә, җәһәт кенә пәкесен бүрәнә ярыгына кыстырып, көтү кайта дип, малайлар белән чыгып та йөгерде. Мин, ике якка аерылган күлмәгемне бергә җыеп, түбәтәйдән 6-7 кузакны кесәләремә салдым. Борчаклы булуын булдым, тик күлмәгем дә кызганыч. Шунда гына әни искә төште, ул ни эшләтер дип, елый-елый өйгә чыгып киттем. Әйе, әни кирәкне бирд-е-е. Чын-дөресен аңа сөйләмәдем, билгеле. Бу гамәлдә Рифкать абыйның гаебе юк иде бит,

үзем риза булдым. “Ничек умырдың, шулай рәтлә!”-диде әни, сүзен төгәлләп. Ярый әле апалар белән үскән Мәүгыйдә тегү-чигү эшләрен маташтыра белә, күлмәкнең киселгән ике кырын бергә типчеп, тегеп куйгандай итте.

Менә хәзер шуларны искә төшереп, уйлап утырам. Киләчәктә медицина галиме, танылган оста хирург булачак Рифкать абый, шул вакытта ук, операция ясау ысулын кулланып, миндә тәҗрибә үткәргән ләбаса. Әнә ничек пәке белән эшне бик тиз дә, оста да башкарды бит. Әле аның үз һөнәре буенча дан-шөһрәт казануында минем күлмәгемнең дә өлеше “з-у-р” булган икән. Ул вакытта күз яшьләремне түксәм дә, бүгенге көндә бу вакыйганы мин елмаеп, көлеп искә алам.

Ә менә монысы шук малай Рифкатьнең үзе белән булган хәл. Танышып узыгыз.

Авылда кышкы салкыннарда кечкенә мал-туарны өйгә кертәләр бит инде. Бигрәк тә тиз туңучан кәҗә, сарык бәрәннәрен (әле яңа туган бозауны да кертәләр). Гадәттә алар мич арасына ябып куела. Беркөн Рифкать урамнан кайтып керә дә, итекләрен сала-салышка, никтер ябылудагы бәрәннәрнең ишекләрен ача бит. Бу вакытта әнисе Рәхимә апа бәрәңге әрчеп утырган була. Иреккә чыккан бәрәннәр, сөенечләреннәндер инде, күзләренә ак-кара күренмичә, дәррәү чабыша башлыйлар: сәкегә дә, өстәл өстенә дә менеп өлгерәләр. Ә бер мәлгуне барысын да уздыра: җәһәт кенә Рәхимә апаның алдына ук сикереп тә менә, суы-бәрәңгесе белән табакны әйләндереп тә төшерә. Бу хәлне көтмәгән-уйламаган хуҗабикә әсәренеп урыныннан сикереп тора. Рифкать тә әнисе янына атылып килеп җитә. Рәхимә апа:”Ник чыгардың аларны?”, - дип кычкырып җибәрә һәм, үзе дә сизмәстән, кулындагы пычагы белән малайның баш өстендә селтәнеп ала. Аның, билгеле, баласына пычак белән сугам дигән уй башына да килми, әмма пычак үз эшен эшли: тиктормас малайның нәкъ уң кашы өстенә үткен ягы белән килеп эләгә. Маңгайдан гөжләп кан китә. Каушаудан ни эшләргә дә белмәгән ана кеше улын кысып кочаклый да: “Тизрәк брачны чакырыгыз!”- дип, өйгә кайтып кергән икенче улына кычкыра. Алай да башы эшләп өлгерә: башындагы яулыгын тартып алып, ярага баса. “Брач” булган фельдшер апа яраны бәйли, кан агуны туктата.

Ә тиктормау нәтиҗәсендә ясалган җәрәхәт–“бүләк” гомерлеккә маңгайга “ябышып” кала.Шулай итеп, булачак хирургның гомерендә беренче операциясе үзендә үк ясала.

Күңелле уеннары, шатлык-сөенечләре, кайчак борчу-кыенлыклары, төрле тамаша-маҗаралары белән кабатланмас балачагыбыз, яланаяклы

һәм бишмәтле булса да, төшләргә кереп, исләргә төшеп сагындыра торган гомеребезнең алтын бер чоры булган икән...

## Күңелгә якын үсмерчак.

Үсмер Рифкать җәйләрен әтисе белән печән чаба, яшьтәшләре белән болын-әрәмәләрдә балан, гөлҗимеш, чикләвек, җиләкләр җыя, “Баллы чишмә” суларын эчеп, беләгенә көч ала. Боз озату, карга боткасы пешерүләр, Пинәрә суларын колачлап йөзүләр, балык тоту, төннәрен ат-сыер саклаулар – болар барысы да үсмерчакның күңелгә иң якын, иң кадерле мизгел-хатирәләре. Үсмерчак белән дә бәйле тагын бер хатирә искә төште.

Кама елгасы, язларын бик нык ташып, авылга кадәр килеп җиткән еллар була иде. Андый елны бөтен болын-әрәмәлекләр, су астында калып, җәй урталарында гына җир кипшерә башлый. Менә шундый бер язда хисапсыз күп булып кумак үрчеде (йорт, су күсесен бездә шулай атыйлар). И-и, кинәнделәр инде үсмер малай һәм яшь егетләр кумак тотып! Минем Әнвәр абыем да тотты ул кумакларны.Киптерергә куйган тиреләрен кошлардан миңа сакларга куша иде.

Нигә кирәге бар ул кумакның дисәгез, бу җанварның тиресе кыйммәт тора. Ул заманда фабрикалар аннан хатын-кыз туннары, мантолар тегүе турында ишетеп белә идек. Тунап (аны кырда ук башкаралар) киптерелгән тиреләрне икенчел чимал җыючылар-заготовительләр җыялар һәм аның өчен әйбәт кенә хак түлиләр иде.

Менә шундый елны Рифкать тә, башка малайлар кебек, меңгә якын кумак тота. Аларны вәземләп туный (менә бит, тагын ничәмә ничә кече “операция”), кыйммәтле “товар”ны энекәшләр саклый. Тиреләр тапшырган өчен байтак кына сумма акча керә. Бу акчага шул елны ат сатып алалар, гаиләне туендыру өчен бу бик зур матди ярдәм була.

Бу вакытта әти-әнисе дә инде олыгаеп баралар. Ике энесе әле кечерәкләр, ә абый-апаларының үз тормышлары. Йорт-хуҗалык мәшәкатьләренең күбесе үсмер Рифкать өстендә була. Инештән көнгә унбишәр көянтә су ташу, бәрәңге утау-өю, кайткан печәнне урнаштыру,

мичкә утын әзерләү, ишек алды, капка төбен себереп чиста тоту һәм башка шундый эшләр аның өстендә була.

Ул чорда мәктәпкә кирәкле уку әсбапларын үзең сатып аласы иде. Без, авыл-малай кызлары, моның өчен әти-әниләрдән акча көтеп утырмадык. Болын-әрәмәдә нәрсә җыярга була, шуны җыйдык. Рифкать тә, язын тал каерысы кубарудан башлап (аны шулай ук киптереп, төргәк итеп бәйләп, заготовительләргә тапшырасың, аны буяу ясауда кулланалар дип сөйлиләр иде), җәен җиләк, карлыган, көзен гөлҗимеш, чикләвек, балан җыеп, аларны саткан-тапшырган акчага өстенә киемсалым, мәктәпкә китаплар алырга акча эшли.

Мөгаен, нәкъ шул елларда ук, үсмер егеттә тырышлык һәм үҗәтлек, мөстәкыйльлек, үз-үзенә нык ышану, кыенлыклар алдында туктап калмау, якыннары һәм башкалар турында кайгырта белү кебек сыйфатлар киләчәктә сайлаячак һөнәренең нигезенә таш булып салынганнардыр.

## Студент еллары.

Бу еллар турында мин әллә нәрсә яза алмам. Чөнки без бер шәһәрдә, бер институтта укыган кешеләр түгел. Шулай да, үзе һәм дуслары, туганнары һәм якыннары сөйләгәннәрне гомумиләштереп, бераз бәян итеп узам.



Күңелле мәктәп еллары артта кала. Чыгарылыш кичәсеннән соң яшь егетләр-кызлар, күңелләрендә йөрткән хыял-максатларына ирешү өчен, төрле якларга таралышалар. Төпле белем алу турында хыялланган Рифкать тә башкалабыз Казанга юл тота. Аның хыялы – капитан булу.Болында җиләк, гөлҗимеш җыйган чакларда, Кама өстеннән гудок бирә-бирә узучы ак пароходларга карап, аның капитан буласы, шундый ук ак пароходлар йөртәсе килә.

Әмма хыял-теләкләрне язмыш бер мизгелдә башкача хәл итә. Егет укырга медицина институтына керә. Авылдан килгән егеткә тел белән бәйле кыенлыкларны да, матди якның авырлыкларын да байтак татырга туры килә. Әмма, авылда ук тормыш тәҗрибәсе туплаган, белем алуга дәрт-дәрманы ташып торган студентка болар гына киртә була алмыйлар. Ул башы-аягы белән белем дөньясына чума: лекцияләрдән соң китапханәләрдә өстәмә әдәбият укый, эзләнә, тапкан-белгәннәрен семинарларда куллана, чыгышлар ясый, үзенең тирән белемле булуын күрсәтә. Ә төннәрен вокзал-пристаньнәрдә товар бушата, больницаларда кизү тора, ягъни, үз тамагын үзе туйдыра.



Шулай итеп, шаулап-гөрләп торган студент еллары сизелмичә үтеп тә китә. Бу еллар уку һәм эштән генә тормаган, әлбәттә. Рифкать тә иптәшләре белән төрле кичәләргә, концерт-театрларга йөри, спорт ярышларын карый, үзе дә студент тормышында актив катнаша.



Рифкать Таҗиев, институтны тәмамлап, бер ай армиядә хезмәт иткәннән соң, табиб-хирург булып эшли башлый. Озакламый яшьлектә сайлаган пары белән гаилә кора, тиздән кызы Гүзәл туа. Тик кадерле кешесе генә бик иртә бакыйлыкка күчә. Кызы, әтисе юлыннан китеп, врач һөнәрен сайлый. Бүген ул онкология шифаханәсендә маммолог булып эшли, медицина фәннәре кандидаты. Чынлап та, юкка гына әйтмиләр бит: “Алма агачыннан ерак төшми”, - дип. Икенче никахтан туган улы Рөстәм дә - врач, ул - УЗИ белгече. (Бүгенге көндә әби-бабайны сөендереп, яраткан оныклар Әмир белән Ралинә үсеп киләләр).




Рифкать Таҗиевның медицинага килү юлында, гомумән, аягы җиңел булды. Бәзәкә мәктәбен бетергән күпме егет-кызларга, матур үрнәк күрсәтеп, аларны үз артыннан ияртте бит ул. Чынлап та, авылыбыздан чыккан врачлар күпме икән бездә? Санап-исәпләп карадым – нәкъ 15 дипломлы врач! Үзе бер Менделеевск больницасы! Әле күпме шәфкать туташларыбыз бар.

# Табиблар гаиләсе.

Таҗиевлар гаиләсе турында сөйләгәндә, бер үзенчәлекне әйтеп китәргә кирәк. Авылыбызда алар нәселен, гаиләсен “табиблар гаиләсе” дип атыйлар. Бу чынлап та шулай. Таҗиевлар нәселеннән 11 кеше үзенең гомерен медицинага багышлаган!

- Рифкать Таҗиев – хирург-онколог, профессор, медицина фәннәре докторы;
- Җиңгәсе Шәмсия ханым Лотфиева (Таҗиева) 45 ел Бәзәкәдә фельдшер булып эшләде, халыкка тырыш хезмәт күрсәтте. Ул I категорияле шәфкать туташы.
- Гүзәл Рәфкать кызы Таҗиева – маммолог, медицина фәннәре кандидаты;
- Рөстәм Рәфкать улы Таҗиев – УЗИ белгече;
- Энесе Камил Таҗиев – терапевт. Питрәчтә 35 ел тырыш хезмәт куйды;
- Рузилә Юсупова-Таҗиева (Мулланур абыйсының өлкән кызы) - Киров шәһәрендә 25 ел врач-стоматолог булып эшләде;
- Резидә Хәлимова –Таҗиеваның (Мулланур абыйсының кече кызы) улы Ренат - нарколог;
- Камалетдинова -Таҗиева Гөлфия (икетуган апасы) - Арчада 35 елдан артык фельдшер булып эшләде;




- Җиһаншина -Таҗиева Люзия (икетуган Шәйхенур абыйсының кызы) – “Шифалы Су” курортында шәфкать туташы булып эшли;
- Таҗиев Рәфис (икетуган энесе) – табиб-ветеринар;
- Таҗиева Рәмзия (Таҗиев Рәфиснең хатыны) – Менделеевск шифаханәсенең шәфкать туташы.

Менә шундый шәфкать ияләрен тудырган, үстергән туган авылыбызның данлыклы һәм мактаулы гаиләсе, нәселе бу.

Нәсел дигәннән, Таҗиевларның бөтен династиясен күзалларга теләсәк, менә шушы шәҗәрәгә – тормыш агачына күз салу да җитә.

Нинди зур, мәгърүр, күптармаклы агач! Мин аны үзебезнең туган ягыбызда үсүче нык агач – имән дияр идем. Ә “имән” сүзе татарда “иман” сүзе белән охшаш. Иман булган җирдә тәртип-тәүфыйк, әдәп-әхлак, күңел аклыгы, җан сафлыгы була. Тамырлары тирәнгә киткән таза, нык бу агачка бернинди җил-давыллар да, яңгыр-бураннар да зыян сала алмый. Әйтәләр бит:


> Җир өстенә аумас өчен
> Ныклап үскән тамыр кирәк.
> Изгелекләр эшләү өчен
> Иман дигән терәк кирәк.

Әйе, нәкъ менә иманлы кешеләр генә башкаларга карата шәфкатьле, мәрхәмәтле булалар.

Әле бу агач Сөембикә манарасына да охшаш кебек. Ул да бит биеклеккә, күкләргә ашкан. Аңа давыл-гарасатлар ябырыла, яңгыр-яшеннәр камчылый үзен, әмма ул нык тора: аумый, егылмый. Сөембикә үзе дә, милләтенең горур, көчле кызы, аянычлы язмышына карамастан, халкым, динем, телем дип җан аткан. Әнә бит, һәр яхшы фикерне, татарның зыялы ул-кызларын мактау-данлау сүзләрен халкыбызга җиткерергә ашкынып торучы журналист Фәния Хуҗәхмәт ничек яза: “Профессор Таҗиев – халык хирургы. Түрәләрне, байларны дәвалаучылар табылыр ул. Ә гади халыкны?.. Менә нәкъ Рифкать Таҗиев кебекләребез гади халыкны сортларга аермый гына тәнен-җанын дәвалый”.

Күркәм нәселнең тормыш агачы Имән һәм татар халкы тарихы, язмышының символы – Сөембикә манарасы арасында шундый охшашлык күрәм мин.

## Өем-йортым – гөлбакча.



Рифкать Минһаҗ улы гомере буе калада эшләп яшәсә дә, күңеле белән ул туган ягын, туган авылын, авылдашларын һич кенә дә онытмый – җәен дә, кышын да Бәзәкәгә сукмакны суытмый. 70 яшьлек юбилее үткәннән соң, туган ягына күченеп кайта, Яр Чаллы шәһәрендә эшен дәвам итә. Әле алай гына да түгел, әти-әнисе яшәгән, гомер иткән, үзләре туып-үскән нигездә өй салырга уйлый. Дусты Хуҗиәхмәтов Әнвәр (урыны җәннәттә

булсын) яңа йортны зур, иркен урында төзергә күпме генә әйтсә дә, Рифкать Минһаҗ улы нигезен ташламый, шул урында яңача мәһабәт йорт төзеп, хатыны Гөлүсә белән авылча тормыш алып баралар. Йортта, ишегалдында, бакчада – һәр җирдә тәртип, пөхтәлек, чисталык аларда. Бакчаларында нинди генә җиләк-җимеш, яшелчә үсми: кавын,карбыз, виноград, төче чия дисеңме! Албакчаны, ишек алларын аллы-гөлле чәчәкләр, безнең якта сирәк үсә торган әллә нинди агач-куаклар бизи. Тырыш хезмәтләренең күркәм нәтиҗәләре дә юк түгел. Бер елны алар үстергән кабакларга (берсе - 75 кг иде!) Чаллы каласында үткәрелгән “Чәчәкләр бәйрәме” ндә I урынны бирделәр.



Гөлүсә ханым чын һәвәскәр бакчачы икән. Җәен көн дә иртән 4тә - 5 тә торып, һәр куак-үсентесен тикшереп чыга ул. Кайсы үсемлеккә кайчан, нинди ашлама бирергә, куак-агач ботакларының кайсыларын кисәргә, кайсыларын калдырырга, карбыз-кавыннарны ничек дөрес формалаштырып үстерергә, кыяр-помидордан ничек мул уңыш алырга – болар һәммәсе уңган хуҗабикәнең көндәлек эш-мәшәкатьләре. Әле безгә дә, йөгереп кереп, уңыш алу мәсьәләсендә киңәшләрен бирергә вакыт таба ул. Каян белә ул бу кадәр бакча серләрен?.. Минем соравыма ул, гади генә итеп: “Укыйм, башкаларның тәҗрибәсен күзәтәм, чагыштырам, интернетта эзләнәм”,-дип җавап бирә елмаеп. Гомүмән, Гөлүсә ханым уңган-булган, күркәм холыклы, гаҗәеп киң күңелле хатын.

Гөлүсә ханым авылда гына түгел, шәһәрдә дә тыныч кына яши торган зат түгел, ул ире Рифкатьнең аерылгысыз юлдашы, аның уң кулы. Алар кайда да, кайчан да бергә. Табиб Таҗиев операция




бүлмәсендә булса, Гөлүсә ханым аның кабинетында яки ишек төбендә иренең катлаулы операцияне исән-сау ясап чыгуын көтә. Үзе эчтән генә туктаусыз кабатлый: “И, Раббым, ярдәмеңнән ташлама, берүк бар да яхшы булсын, уңышлы чыксын, авыруы терелеп, аякка басарга насыйп ит.” Кайбер көннәрне катлаулы операция 6-8 әр сәгать бара.

Кулына скальпель тоткан врачны күз алдына китерегез. Шушы кадәр сәгатьләр, бер урында басып торып, аяклар шешә, гел иелеп эшләгәнгә, арка-муен таштай ката, куллар оеый, күзләр тала, тамчылар булып тир ага. Мондый операциядән соң хирург нинди хәлдә-халәттә була икән? Моны Гөлүсә ханымнан да яхшырак белүче юктыр. Операция беткәннән соң, ял бүлмәсендә ул иренә шифалы-үләнле чәйләр эчертә, арган талган күңелен тынычландырырдай сүзләр таба. Җыеп кына әйткәндә, профессор Таҗиев – авырулар өчен, ә Гөлүсә Миннегали кызы – Рифкать Минһаҗ улы өчен яклаучы-саклаучы фәрештә.

Яңа эш урыны авылга якын урында булгач, Таҗиевлар атна саен ялларга кайтып йөриләр. Хәер, исеме генә ял аның. Шушы көннәрдә дә тынгы юк аларга. Капка төбенә машиналар килеп кенә тора. Менделеевск, Чаллы, Алабугадан, Әгерҗе якларыннан ук киләләр. Тик алар бит күрешү, хәл белү өчен түгел, ә үз гозерләре, борчу-мәшәкатьләре белән киләләр. Рифкать Таҗиев аларның берсен дә кире бормый. Башлаган эшен калдырып, һәрберсен сабырлык белән тыныч кына тыңлый, карый. “Бүген килүчеләр бигрәк күп булды, планлаштырып кайткан эшләрнең яртысын да эшләп булмады”,- ди, Гөлүсә ханым. Юк, иренә үпкәләми ул, чөнки аның килгән кешене кабул итмичә, чыгарып җибәрмәсен белә ул.



“Мин авыру кешене борып чыгара алмыйм. Ул минем күземә генә түгел, җаныма карый кебек”,-ди табиб Таҗиев үзе.

Әле тагын бер нәрсә гаҗәпләндерә мине бу кешенең холык-фигылендә. Менә бер мисал. 1 май, якшәмбе көн. Рифкать Таҗиевның бүген туган көне. Күрәм, күршеләрем машина янында торалар, китәргә җыеналар булса кирәк. Алар янына чыгам:

- Ник болай бик тиз китәргә булдыгыз әле ?

- Операция ясаган авыруым бар, хәлен белергә кирәк,-дип җавап бирә Рифкать абый.

Менә сиңа ял, менә сина туган көн... Ә бит телефон бар, хәлне сорашып та белергә булыр иде. Юк шул, табиб Таҗиев андыйлардан түгел! Аңа үзе операция ясаган авыруны үз күзләре белән күрергә, янында булырга, хәлен белергә, ерактан килүче яки янына килүче булмаганнарга өендә тавык шулпасы пешереп тә алып килергә, сырхауның күңелен күтәреп җибәрергә кирәк.

Әйе, хирург хезмәте бик авыр хезмәт, үлем-җитемнәрсез генә узмый, бигрәк тә онкологиядә. Мондый вакытта врач үзе ярты үлә: борчыла, үртәлә, төннәрен йоклый алмый. Боларның берсен дә авыруларга күрсәтергә ярамый, барысын да эчкә йотасы. Шушы гомер эчендә гаиләсендә, нәселендә үзенең дә күпме якыннарын, туганнарын югалтты ул.Ә бу авыр кичерешләр эзсез генә узмый бит. Табиб та кеше ич, тимер түгел. РифкатьТаҗиевның да йөрәге түзми, бер мәлдә аздан гына туктамый кала. Ярый әле тиз арада Мәскәүдә операция ясыйлар үзенә. Исән-сау терелеп аякка басуга, ул тагын үз эшенә керешә.

Алга таба да табиб Рифкать Таҗиевка уңышлы һәм хәерле гамәлләр генә насыйп булсын!

**Бу урында, мин язуымнан туктап, укучы игътибарына газета-журнал материалларын тәкъдим итәм.**

**Әхмәт Гадел**
**«Ватаным Татарстан» газетасы, 12 октябрь 1993 ел.**

# Бәхетле кеше

Шәһәр буйлап, яңа кварталлар буйлап ыспай гына киенгән, җитез хәрәкәтле бер кеше бара. Зур букча тотып, азык-төлек, төрле тәм-том җыеп кайтырга чыккан. Иртәгә – Җиңү бәйрәме, ә аның үзенә исә илле яшь тула.

Бу кешене – Рәфкать Минһаҗ улы Таҗиевны мин бик күптәннән беләм төсле. Бу дөньяда яшәвемә, гомерем киселмәгәненә аның турыдан-туры катнашы бар. Бер көнне өйгә кайтып килгәндә бөгелдем дә төштем. Ходайга шөкер, янәшәмдә олы композиторыбыз һәм кешелекле, ярдәмчел кеше Әнвәр ага Бакиров бара иде. Ул өйгә кайтып җитәргә ярдәм итте. Авырту да беткән сыман булды.

- Я, алайса, бүгенгә түз инде, әллә нәрсә булмагандыр, - диде хатыным.

Без бит эчәк шартлаганын белмибез. Шул вакыт дустым Рәфкатькә шалтыратырга булдым. Ләкин кинәт телефон зыңлады. Инде бер ел чамасы ишетмәгән тавыш – Рифкать тавышы яңгырады. Ул хәлләремне сораша.

- Дустым, Рәфкать! – дим. – Хәлләргә килсәк, бик үк шәп түгел. Сукыр эчәк тирәсе бик нык бора, - дидем.

- Көт, утыз минуттан булам! – диде ул. Һәм, “Ашыгыч ярдәм” машинасында килеп тә җитте.

Без Рәфкать белән җитмешенче еллар уртасында таныштык. Түбән Камада чыга торган “ Ленин нурлары” газетасының мөхәррире Николай Евсеевич Кузнецов бик каты авырып, шушы хастаханәгә китерелгән иде. Үпкәсенә операцияне хирург Рәфкать Таҗиев ясады. Дүрт сәгатьтән артык без берничә дус – Николай Евсеевичның якын шәкертләре карап тордык. Шунда хирург эшенең нинди авыр, нинди җаваплы, нинди катлаулы икәнлеген күрдем. Хәтта күзәтеп торуы авыр булды безгә. Арабыздан беребез һушыннан да язды, алып чыгарга мәҗбүр булдык.

Хирург Таҗиев турында ул чакта язып та чыгарырга йөргән идем. Әмма бу темага өлгермәгән булганмын. Яза алмадым. Рәфкатькә исә бер шигырь багышладым:

Ак халатлы, пакь күңелле кеше,
Эреттең син язмышның
карларын.
Соңгы сулышларым дигән чакта,
Бүләк иттең тормыш таңнарын.
Ак карларны язгы кояш җиңә,
Җир-гүзәлкәй ничек яшәрде!

Доктор дустым, кояш җанлы
кешем,
Мин яшимен әле, яшәрмен!
Алсу гөлләр бүләк итәм сиңа, -
Гомерлеккә минем рәхмәтем.
Доктор, доктор, ак фәрештәм
минем,
Булсын сиңа дөнья рәхәте!

Яльчик район хастаханәсендә эшли, баш врач була, республикада таныла. Тарихны, әдәбиятны яхшы белгән бу зыялыбыз анда эшләгән елларын болай искә ала:

- Яльчик район хастаханәсендә эшлим. Тиз арада күтәрелеп тә киттем. Башлык иттеләр. Уйламаган да идем. Миңа кадәр унике чуваш баш врачы эшләгән. Врачлар белән уртак тел таба алмыйча тилмергәннәр. Хастаханә эше белән шөгелләндем, табибларның тормыш-көнкүрешләрен яхшырттым, аларга яхшы эшләү өчен шарт бирдем. Гайбәт җыймадым. Кешеләрне талаштырмадым. Гайбәт, шикаять һәм башка шундый начар эшләргә юл куймадым. Үзем генә дөресен ачыкладым. Тора-бара зарлар, шикаятьләр туктады. Табиблар үз эшләре белән генә шөгельләнә башладылар. Хастаханә Чувашиядә беренче урынга чыкты. Татарстаннан да, чиктәш районнардан да килә башладылар.

Анда эшләгәндә Рәфкатьнең орденатура бетерү теләге, белемен арттыру нияте уяна. Рак авыруын дәвалау ысулларын эзләү еллары иде. Рәфкать бигрәк тә борчылды. Үз тормышында шул яман шештән рәнҗетелгән, якын кешеләрен җуйганнары булды аның. Шулай итеп, ул Казанга кайту турында хыяллана, туган җир, ана теле, газиз халкы аның күңел түреннән бер генә чакта да төшеп калмады, югалмады.

Ул – бүгенге Менделеевск районының Бәзәкә авылында туган егет. Тойма суы белән Кама кушылган җиргә урнашкан бу гүзәл, табигый матурлыкка бай авыл. Авыл зур, аның ике мәчете, ике мәхәлләсе булган...

Ун сыйныфны дүрт белән бишкә тәмамлаган Рәфкатькә әти-әнисе ничек тә тиз укып бетереп, урынга керергә кушалар. Ә егет табиб булырга хыяллана. Шулай да, ата-ананы да тыңламыйча булмый, дип уйлый ул. Уйлый торгач, ул, Чистай елга училищесына керергә дип, пароходка утыра. Ходайга шөкер, аттестатларны алып утыручы урта яшьләрдәге бер абзый, аның дүртле-бишлеләрен күреп, институтка –

Казанга барырга киңәш итә. Шулай итеп, егет Чистайдан Казанга китеп бара.

Рәфкать Таҗиев Казан дәүләт медицина институтының дәвалау факультеты студенты булып китә.

- Ул елларны намус, вөҗдан, кешенең кешегә мөнәсәбәте шактый күркәм булган икән. Олылар да әле ул кадәре бозылмаган, акча сихеренә бирелмәгән. Хәзер булса, керә алыр идемме икән? Шикләнәм. Чөнки ни бай әти-әнием, ни югары дәрәҗәле туганым юк...

Рәфкатькә ярдәм итеп, акча җибәреп торучы кешесе булмый. Казанның товар станцияләрендә, елга портында, завод-фабрикаларда, төзелештә, урам төзекләүдә һәм себерүдә эшли. Үз көнен үзе күрә, белем ала. Ә инде бераз белем алгач, өченче-дүртенче курсларда хастаханәләрдә эшли башлый. Төннәрен кизү тора, авыруларга дарулы инә кадый, палаталарны тәртипкә кертә. Миһербанлы, кайгыртучан, йомшак күңелле була. Шуңа күрә аның үзен дә ихтирам итәләр.



Ә инде үзе укып чыгып эшли башлагач, кечерәк туганнарына ярдәм итә. Шул ук вакытта үзе дә укый, эшләп укый. Кандидат дипломын яклый, табиблык буенча олы белемгә ия була.

Аның турында сүз чыкканда, аны белгән кем белән генә сөйләшмә – бергә эшләгән Б. Дружковмы ул, А. Солнышкинмы, яисә башкалармы – Рәфкать Минһаҗевичны сүзендә торучан, кешеләр турында кайгыртучан, кул астында эшләгәннәргә ярдәмчел, аларның хәленә керә белүчән кеше, диләр. Ә авырулар исә савыкканнан соң рәхмәтен укыйлар, дога кылалар. Чөнки аның операцияләре искиткеч уңышлы була, кулы җиңел. Бу, әлбәттә, - ихлас күңелдән, адәм баласына саулык теләп эшләүнең нәтиҗәсе.

Аның хирург эшен һәм авыруның хәлен җиңеләйтү өчен ясалган җайланмалары бөтен дөньяда танылды һәм куллану тапты. Боларның кайберләре онкология өлкәсендә генә түгел, гомумән, операция ясаганда кулланыла.

Бүген Рәфкать Минһаҗ улы Таҗиевның докторлык диссертациясе әзер. Мин үзем моңа бик ышанам. Чөнки Рәфкатьнең үз максатына тайпылмыйча, нык адымнар белән бара белгәненә бик күп мәртәбәләр шаһитмын.

Менә инде ничәмә-ничә ел дәвамында ул онкология өлкәсендә эшләп, хәтәр һәм афәт булып кеше башына төшкән бу авыруны дәвалау ысулларын эзли, үзенең сөекле остазы мәрхүм М. Сигалның юлын озайта, яңача, үзенчә – Таҗиевча – бу юлның дәвамын сыза. Һәм тагын шуны әйтим (бу хакта әйтми калсам, дөрес булмас иде): аның гомер юлдашы Рушания ханым да һәм кызы – әтисенең юлын сайлаган Гүзәл дә, аңа бик күп булышалар, аның белән теләктәшлектә яшиләр. Бу авыр хезмәтне бик күпкә җиңеләйтә, иҗатның томанлы урыннарын яктырта, эзләнүләрне табышлы итә.

- Мин бәхетемне яраткан эшемдә таптым. Үз эшемне, үз хезмәтемне ихлас күңелдән ратканга күрә, миңа эшләве дә җиңел тоела. Мин кешегә гомернең мизгелләрен бүләк итәм. Бу бит кешенең үзе өчен генә түгел, аның тирәсендәгеләрнең дә, күңеленә хушлык бүләк итү. Мин үзем шулай уйлыйм...

Әйе, бу кеше белән дус булу минем холкыма да шактый тәэсир иткәндер. Әлбәттә, үзем дә бала чактан бирле хыялланган һөнәремә ия булдым, үзем дә бәхетле. Бу очракта без Рәфкать белән тиңнәр. Гаилә бәхете дә, Аллага шөкер, бер-беребезнекеннән ким түгел. Икебез дә кеше өчен яшибез. Моңа ничек куанмыйсың инде? Ләкин бу куанычымны кешеләргә дә җиткерәсем, күрсәтәсем килә. Халкыбызның һәр улы, һәр кызының бөеклеккә, алдынгылыкка омтылуын яратам һәм хуплыйм. Үз хезмәтең, үз тырышлыгың, Ходай биргән сәләтеңә алган белемеңне кушып, алга чыгу тарафдары мин.

Менә шуңа доктор Рәфкать Таҗиев турында милләттәшләремә сөйләргә кирәк дип таптым.

**Альберт Хәсәнов**
**12 май 1996 ел,**
**“Ватаным Татарстан”**

## Кояшым сүнгәндәй булды

Менә ни вакыт кулыма каләм ала алмыйм. Һәркөн өстемә чыга торган кояшым сүнгәндәй булды. Хәтта ике-өч көнлек кенә сәфәрләрдән дә хатыным, балаларымнан болай сагынып кайта торган эш өстәлем дә юатмый. Бу юлларны, күземә яшьләр тыгылган хәлдә,

үкси-үкси язам. Кәгазь битендәге бу таплар минем күз яшьләрем. Өстебезгә, таулар ишелгәндәй, зур кайгы килде гаиләбезгә. Гәрчә беркемне рәнҗетми, хәләл ризыгыбызны үз көчебез белән табып, иман, намус белән яшәсәк тә. Өзелеп сөйгән олы кызым Гөлнараны җирләдек. Әле утыз дүртенче яше белән генә бара иде. Бик дус идек без аның белән, яратыша идек. Яратмаслык та түгел, биесә ут чыгарып бии, утырса, коеп куйгандай тегә иде. Кызыбыз бик чибәр ханым, киявем Нәфиснең сөйгән тормыш иптәше, оныгым Арысланның яраткан әнисе иде. Бик уңган бала булды ул. Урта мәктәпне алтын медальгә бетереп, Мәскәү институтын да кызыл дипломга тәмамлап кайтты. Тормыш юлын Лениногорск нефть техникумында комсомоллар башлыгы булып башлаган иде.

Аннары тормышка чыкты. Туй ясадык. Иптәше аны Себергә алып китте. Җиде елга якын яшәделәр бугай. Балабыз шуннан авырып кайтты. Бер-бер артлы һәркайсы җидешәр сәгатькә сузылган авыр операцияләр кичерде. Казан онкология шифаханәсе профессоры Рифкать Минһаҗ улы Таҗиевкә без мең рәхмәтле. Кызыбызның гомерен беразга гына булса да озайту өчен ул барын да эшләде. Институт сабакташым, бүген Премьер-министр урынбасары Илгиз Кәлимулла улы Хәйруллинга да без мең рәхмәтле. Ул безгә нинди генә дарулар табышмады. Кызыбыз өчен үзебез дә кулдан килгәннең барын эшләргә тырыштык. Ләкин булмагач, булмый икән. Профессор Р. Таҗиевнең алдына тезләнеп:

- Өстәлгә кызым белән янәшә сал. Кайсы әгъзам яраса, шуны кисеп ал, тик кызым гына яшәсен,- дип ялындым...

Профессор Р. Таҗиев өстәленә бик соңарып яттык шул...

Адәм баласына кайгы-хәсрәтсез яшәргә язмаган, күрәсең. Үлгән артыннан егылып үлеп тә китеп булмый икән. Яшәргә тырышырга кирәк. Мин бу юлларны яшьләремә тыгылып язам... Әгәр инде сезнең күзләрегезгә яшь килсә дә кайчак, алар тик минем шаян, көлкеле хикәяләремне укыганда гына күренсен.

**Михаил Розенгартен, медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган табибы**

**“Ватаным Татарстан” газетасы, 1999 ел.**

## Кеше булган кешедә йөз кешенең эше бар.

Кеше ышаналмаслык хәл: хирург бер операция вакытында хастаның бик мөһим алты әгъзасын кисеп ала. Нәтиҗәдә ракның азган төре белән авырган сырхау исән кала. Алай гына да түгел, эшләү сәләтен дә югалтмый. А.га 49 яшь, һөнәре буенча ул механизатор. Аны район хастаханәсенә ашказаныннан бик көчле кан килгән хәлдә китерәләр. Ашыгыч ярдәм күрсәткәч, авыруны санитар самолет белән республика онкология үзәгенә алып киләләр.

Бер минут вакытны да сарыф итмичә, ул чагында әле Казан дәүләт медицина академиясенең хирургия һәм онкология кафедрасы доценты Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев аңа операция ясарга керешә. Операция бик катлаулы була. Ашказаны, ашказаны асты бизенең шактый өлеше, талак, бавырның сулъяк өлеше, аркылы-кайма эчәк, бөер асты бизе кисеп алына. Бу көннән соң инде күп вакыт узган. А. җәй көннәрендә механизатор хезмәтен дәвам итә. Үлемнән йолып калучысы янына еш килә.

Хирург булып эшли башлаган көннән үк ( Чувашия, Яльчик районының үзәк хастаханәсе) Рифкать Минһаҗ улы медицина диагностикасын камилләштерергә һәм хирургиягә яңа алымнар кертергә омтыла. Озакламый хастаханәнең мөдире эштән китеп бара һәм Рифкать аның урынында кала. Ул көнне төнгә ялгап эшли: вакытында йоклау, туклану онытыла. Тәүлек буе хастаханәдән чыкмаган көннәре күп була. Операция өстенә операция – ясап кына өлгер.



Яшь табибның абруе көннән-көн үсә. Тагын бер елдан хастаханәнең баш табибы да эштән китә. Рифкать Таҗиевка ике ел буена баш табиб һәм хирург вазифасын башкарырга туры килә. Районда эшләү срогы тәмамланыр алдыннан ул ГИДУВта онкология һәм хирургия буенча белемен күтәрә. Шунда галим, танылган хирург, профессор Мойша Зельманович Сигал белән очрашу аның киләчәк язмышын хәл итә дә куя.

Яльчикта өч ел эшләгәннән соң, Рифкать Таҗиев профессор Сигал клиникасында ике ел ординатура үтә һәм аны Республика онкология диспансерының хирургия бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Монда да табибны яңа мәшәкатьләр көтеп тора: бүлектә ремонт эшләре бара. Стена-түшәмне акшарларга, идәнгә линолеум җәяргә, бүлмәләрне аппаратлар һәм җиһазлар белән тәэмин итәргә, кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Ул елларда бередә оста хирурглар Н. Поляков, Х. Кәримов, анестезиолог А. Подольский эшли. Яшь белгеч алардан корсак өлешендәге, аннары күкрәктәге яман шеш авыруларына ясалган операция алымнарын өйрәнә. Эшкә хирыслыгын күреп, аны 1980 нче елда клиника ассистенты итеп билгелиләр. Бу елларда ул бик мөһим темага диссертация яза һәм аны 1983 нче елда “Спленопанкреатогастэктомия в хирургии рака желудка”темасына кандидатлык диссертациясен яклый. 1985 елда профессор Рифкать Минһаҗ улы доцент итеп сайлана, ә 1990 елда профессор  Сигалның выкытсыз үлеменнән соң хирургия һәм онкология кафедрасы мөдире итеп билгеләнә.

1997 елда ул Мәскәүдә “Одномоментальные операции в хирургическом лечении рака пищевода и кардиоэзофагеальной области» темасына докторлык диссертациясен яклады. 1998 елда исә аңа Югары аттестация комиссиясе профессор дәрәҗәсен бирде.

Мөгаен, онкология өлкәсендә ул ясамаган операцияләр юктыр. Ә бит кешенең организмына карап һәр операция үзенчәлекле, бер-берсен кабатламый. Көтмәгәндә төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Мондый вакытта табибның югалып калмавы сорала.

Катлаулы операцияләрдән соң, профессор аудиториягә лекция укырга ашыга. Аның дәресләренә яшь дәвалаучылар гына түгел, Казанның һәм Рәсәйнең төрле төбәкләреннән табиблар җыйнала. Монда инде ул онкология өлкәсен тирән белүче галим буларак ачыла.

Рифкать Минһаҗ улы белән ни хакында гына әңгәмә корсаң да, аның үз эшенә булган мәхәббәте гәүдәләнә.

Күп гасырлардан бирле мондый гыйбәрә йөри: “Кеше кешегә - бүре”. Ләкин Санкт-Петербургның фән һәм сәнгать академиясе әгъза-корреспонденты, профессор, Татарстан Республикасының атказанган табибы, җитмештән артык фәнни эшләр авторы, Республиканың сәламәтлек саклау Министрлыгы каршындагы Клиника-онкология Үзәгенең дәвалау-диагностика бүлеге җитәкчесе Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев турында сүз барганда, бу гыйбарәне бераз үзгәртеп, болай диясе килә: ”Кеше кешегә – кеше!”.

**Медицинская практика**

**Информационный сайт для специалистов в области медицины, 2011 год.**

# Ранняя диагностика — спасительный круг в онкологии.

На сегодняшний день онкологические заболевания являются не только медицинской, но и социальной проблемой. Существует мнение, что северные народы чаще подвержены раку пищевода. Некоторые врачи объясняют это частым травмированием пищевода любимой едой — строганиной. А южные народы тем же диагнозом обязаны своей традиции пить очень горячий чай. Именно частые ожоги и провоцируют заболевание. В Японии, где в меню доминируют морепродукты, часто встречается рак желудка. В Таджикистане и Узбекистане реже, чем в Европе, встречается рак молочной железы. Онкологи связывают это с тем, что восточные женщины рожают много детей и кормят их грудью. С одной стороны, проблемы разные, но, с другой стороны, всегда одним из решающих факторов в борьбе со страшным диагнозом «злокачественная опухоль» является рациональное использование комплексных и комбинированных методов лечения онкологических заболеваний. О таких методах лечения, использующихся в Республиканском клиническом онкологическом диспансере, рассказал Заслуженный врач РТ, Заслуженный деятель науки РТ, профессор кафедры онкологии и хирургии КГМА, член-корреспондент Петровской академии наук Рифкат Мингазович Тазиев.

— **Рифкат Мингазович, какова в настоящее время распространенность злокачественых опухолей?**

— Злокачественные опухоли возникают в результате злокачественной трансформации (малигнизации) нормальных клеток, которые начинают бесконтрольно размножаться, теряя способность к апоптозу. На сегодняшний день распространенность онкологических заболеваний высокая и отмечается высокая смертность. Ежегодно в Республике Татарстан выявляется более 13 тысяч больных со злокачественными опухолями. Более 6,5 тысяч погибают от этой болезни. Сейчас лидирующее положение занимает рак молочной железы, который вышел на первое место, опередив колоректальный рак.

— **Какие на сегодняшний день в *Республиканском клиническом онкологическом диспансере* существуют новаторские методы лечения злокачественных новообразований?**

— В настоящее время Республиканский клинический онкологический диспансер располагает достаточным арсеналом средств лечения онкологических больных в любой стадии заболевания.

Отмечу, что сейчас успешно и интенсивно развиваются операции с использованием видеоэндоскопии, среди них видеолапароскопические операции малоинвазивные методы хирургического лечения. После таких операций пациенты выписываются уже через двое-трое суток. Это направление продолжает успешно развиваться.

Следует отметить, что по выполнению видеолапароскопических операций по поводу рака пищевода мы являемся лидерами в России. У нас большой опыт накопился по хирургическому лечению распространенных форм опухолей тазовых органов гениталий и рака кишки. Осуществляется полное удаление органов малого таза, что включает в себя удаление мочевого пузыря, гениталий у женщин, прямой кишки с последующим восстановлением удаленных органов (прямой кишки, мочевого пузыря).

Большой прорыв отмечается в лечении рака молочной железы. Этим направлением занимается доктор медицинских наук Артур Халитович Исмагилов. Он внедрил в нашу клинику пластические операции при доброкачественных и злокачественных опухолях молочной железы. Операция заключается в том, что одномоментно удаляется грудь и производится ее восстановление из собственных тканей пациенток.

Радиохирургическое лечение заключается в однократном сверхточном подведении большой дозы ионизирующего излучения к опухоли труднодоступной локализации с применением средств стереотаксической навигации.

# Татарстан Республикасы Президенты Указы

Табигый, техник һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә, принципиаль яңа технологияләр эшләүгә һәм кертүгә зур өлешләре, фән һәм техника

казанышларын кертү нигезендә алынган күренекле производство нәтиҗәләре өчен фән һәм техника өлкәсендә 2011 ел Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырырга һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге лауреаты» исемен бирергә:

«Колоректаль ракны беренчел профилактикалау, иртә диагностикалау һәм дәвалау ысулларын камилләштерү өлкәсендә фундаменталь, гамәли аспектларны эшләү һәм кулланылышка кертү» дигән хезмәт өчен: Таҗиев Рәфкать Минһаҗ улына, медицина фәннәре докторы, Казан дәүләт медицина академиясенең онкология һәм хирургия профессорына.

**Фәния ХУҖАХМӘТ**
**“Мәдәни җомга” гәҗите, 16 май, 2003 ел.**

## Ап-ак атларга атланып төшләргә кергән егет.

***Әлеге концерт - Әлфия Афзалованың 70 яшьлегенә багышланган бенифисы – бик тә авыр, әле 6-7 ел элек кенә бөтен республикабызны, алай гына да түгел, бөтен дөнья татарларын дер селкеткән вакыйга белән башланып китте. Ул чакта бөек җырчыбыз тавышсыз калган иде. Өстәвенә, өч хәрефле яман чир дигән күкле-яшелле хәбәр барыбызны да тетрәндерде. “Израиль табиблары да дәваларга алынмый икән”, - диделәр. Алар шулай, дәваларга тулы ышанычлары булмаса, алынып та тормыйлар. Мактаулы, данлыклы элеккеге обком хастаханәсенә киңәшергә дип тә, нәрсә әйтер дип тә республика онкология клиникасыннан онколог, хирург, профессор Рифкат Минһаҗ улы Таҗиевны чакыралар. Ул чакта легендар җырчыбыз нәкъ менә Рабит Батулла видеотасмага яздырып алып, олуг бәйрәм кичәсендә экраннан зур итеп безгә күрсәткәнчә була... Тавышы да юк, үзен тануы да кыен.***

Зур концерт Әлфия апаның экраннан тавышсыз сөйләве белән башланып китте. И-и, оста да инде бу Батулла да: шундый бәйрәм кичәсендә йөрәкләребезне әчеттереп, күзләргә яшь китерде. Нинди аяныч, бер дә дәвалана алмас кебек. Ул вакытта, Батулла белән озаклап сөйләшкәннән соң, Әлфия апа йокымсырап китә һәм бик матур төш

күрә. Ап-ак атка атланган егет, Әлфия апаны алып, очып китә. Дус-ишләре шикләнәләр, үзе исә: “Терелэм” – ди. Рифкат Таҗины ул елмаеп, терелтүчесе итеп каршы ала, ак атка атланып төшкә кергән егет дип кабул итә.



Шулай булып чыга да, Рифкат Минһаҗ улы аз гына шикләнми дә, икеләнми дә, данына күләгә төшәр дип тә уйламый. Башта Әлфия апаның тавышы кайта, аннан үзе терелеп, аякка баса. Калганы инде барыбызның да күз алдында: дүрт сәгатьтән дә артыграк дәвам итте ул кичә. Арытмады да, ялыктырмады да Әлфия апа. Сөйләде дә, җырлады да, ә икенче көнне бәйрәмен дәвам итәргә Чаллыга китеп барды.

Минем исә ак атларга атланып, коткаручы булып төшләргә кергән егетне күрәсем килде. Беләм, күп мәртәбәләр ишеткәнем бар: кемнеңдер төшенә ул ак сакаллы бабай, кемгәдер гүзәл кыз булып керә. Хәер, кем булса да – коткаручы инде. Җөмһүриятебезнең кайсы гына ягына барып чыксаң да, аны беләләр, ул коткарды, операцияне үзе ясады, дип, сөенеп тә, горурланып та сөйлиләр.

Авыл халкы соңгы ышаныч, соңгы өмет белән күп килә Казанга операция ясатырга. Ашказаны, эчәкләр һәм ашказаны асты бизе – болар Рифкат Минһаҗ улының, кем әйткәндәй, үз өлкәсе, төнлә уятып сорасалар да яттан белгән өлкәсе.

Миңа яшь чагында ук Рифкат абыйны күрергә, аны тыңларга насыйп булган иде. Соңрак ул минем авылдашларымны да, авыр-авыр операцияләр ясап, коткарып калды. Аларның хәлен белергә килгәндә читтән генә күзәтә идем. Күрше апага да, 20 еллап бардыр инде, менә үлә-үлә дигәндә операцияне ул ясаган иде. Әле менә авылга кайтсам, тугызынчы дистәне ваклаган әбиебез, түтәл ясап, суган утыртып йөри. “Коткаручымны догадан калдырмыйм”, - ди.

Рифкат Таҗины концерт, театрларда да очратканым бар. Вафирә Гыйззәтуллинаның соңгы концертында сәхнәгә чәчәкләр чыгарганын да күргән идем. Инде менә күрешергә килгәч, операциядән чыкканын көтеп алдым. Байтактан күргәнем булмаса да, коридор башыннан күренү белән,ерактан ук таныдым. Авыруларыбызның бәхетенә, ул әле һаман яшь, сөйкемле, барыннан да бигрәк, сабырлыгы, гаҗәеп бер ягымлылыгы һәм гадилеге белән сокландырды. Югыйсә, визит карточкасына язылган титулларга караганда, бер дә гади булырга тиеш

түгел кебек. Анда: “Татарстанның атказанган табибы, профессор, онкология һәм хирургия кафедрасы мөдире, Петровский фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы”, дип язылган бит.

Үзем куйган сорауга җавап эзлим. Ничек шулай матур, гади кеше булып кала алган соң ул ? Сәгатьтән артык ашыга-ашыга сөйләшәбез. Минем аңардан күбрәк беләсем килә. Күңелемдәге сорауларга җавап табам да нәтиҗә ясап куям. Шул ук Вафирәмнең күрше авылында – Менделеев районының Бәзәкә авылында гап-гади гаиләдә туып-үскән Рифкат абый. Ләкин тыштан, читтән караганда гына гади ул. Ул чакларда, аның әтисе Минһаҗ абый кебек, Коръәнне яттан да, карап та укый, аз гына кызыксынсаң, тәрҗемә итеп, аңлатып та бирә алган кемнәр генә булды икән?! Әтиләре шуның өчен кыйналса, әниләренең йөрәге сызлый. Бик яшьли гүр иясе буласын сизенгәндәй, әниләре ашыга-ашыга яши. Бер-бер артлы дүрт баласы – ике улы, ике кызы башлы-күзле булып үз гаиләләрен корып өлгерәләр. Минһаҗ абзый 1, 4, 8нче сыйныфларда укучы 3 улы, барлыгы 7 баласы белән ятим дә, тол да кала. Еллары нинди бит әле: кияргә киемең кадерле, ипинең бигрәк тәмле чаклары. Шуңадыр инде, мәктәпне тәмамлап, укырга киткәндә беренче теләк: укыган җирдә ашатсыннар иде, киендерсеннәр дә иде...

Хыялсыз буламыни соң яшьлек, аңа ашау, киенү бөтенләй кагылмый диярсең. Рифкат икесен бергә кушып юлга чыга. Аның капитан буласы, су өсләрендә ак пароходны идарә итәсе килә. Укый-укый шуңа ирешермен, дип, Чистай елга училищесына укырга керергә ниятли ул. Анда ашаталар да, киендерәләр дә.Ләкин документларын әйләндереп-әйләндереп карыйлар да укырга алмыйлар. Мондый яхшы аттестат белән Казанга бар, диләр. Классташы Мулламөхәммәт белән Казан елга техникумына баралар. Нәкъ менә документларны тапшырып, Казан белән танышып йөргәндә класс җитәкчеләре Зәйнак абый очрый. Кирәк бит шулай: нәкъ менә ул хәл итә Рифкат Таҗиевның язмышын. Ничә еллар янәшә яшәгән укытучы үз укучысын беренче күргәндәй: - Син врач булырга тиеш, -ди.

Бар, бар иде ул андый хыял, тик күңел төпкелләрендә күмелеп калды. 8 нче сыйныфны тәмамлагач, ул үзе дә, училищега барып, медбрат булам, дип диктант язып кайткан була.

Зәйнак абыйсы ияртеп үк китә, документларны бер җирдән алып, икенче җиргә тапшыралар. Менә бәхет, анда имтиханнарны гел татарча гына алалар. Икесе – “биш”ле, икесе – “дүрт”ле була. Баш эшләгәч, хәтер яхшы булгач, укыганда татар мәктәбен тәмамлау да, урысчаны авыррак белү әллә ни кыенлык тудырмый. Яхшы укыганга, тырышлыгы

күренеп торгандыр инде, аны Татарстаннан, Казаннан ерак җибәрмиләр. Ул елларда шулайрак була: читтән килгәннәрне, бигрәк тә урыс милләтеннән булса, Казанда калдыралар. Татарстанлыларны, татарларны читкә, еракка җибәрәләр. Ул елларда диплом да бирмиләр икән әле. Алар өчәү – иптәш егете хатыны белән һәм Рифкат Чуашиянең Яльчик районында эшли башлыйлар. Иң зур мәктәпне Рифкат Минһаҗ улы шунда уза. Монда врач хезмәте аерым белгечлекләргә бөтенләй бүленми. Үзе баш, үзе түш, диләрме әле? Бер елга 360 операция генә ясый ул. Үз-үзенә ышаныч та, беренче горурлык та аңа шунда иңә. Ләкин “мин” дими ул, һаваланмый, мактанмый. Бусы инде иманнан киләдер, әмма тыйнаклыкның үсешкә комачаулаган чаклары да була. Ординатурада укыганда остазы – данлыклы хирург Сигал бер генә бурыч йөкли. Миңа аны Рифкат әфәнде бик гади итеп аңлатты.

- Ул чакта, - диде,- ашказаны, ашказаны асты бизе, эчәкләренә операция ясаган 5 кешенең берсе үлеп бара иде. Бу бит 100 кешенең 20се, дигән сүз.

Михаил Семенович шәкертенә бик “җиңел” эш йөкли: менә шуннан котылырга кирәк, ди. Операция ясалган кеше үлмәскә тиеш. Ничек?

Анысын инде Республика онкология клиникасында үзләре генә белә. Юк, дөрес әйтмим, бу турыда бик еракларда да беләләр. Монда операциядән соң үлүләр бөтенләй сирәгәя. Әгәр операцияне узасыз икән, яшисе дә яшисе. Ләкин коточкыч операцияләр була. Әле шушы көннәрдә генә Рифкат Таҗиев нәкъ шундый операция ясый. Югыйсә, киңәшкә генә чакырган булалар, ләкин ул үзе алына һәм уңышлы башкарып чыга.

- Бер операия 11 сәгатькә сузылды – дип сөйләп китте Рифкат абый. Ләкин күз алдына китерүе шактый кыен. Зур кулъяулык кадәр урында 11 сәгать буе нәрсә эшләргә мөмкин. Кистең ди, чистарттың ди, ялгадың ди, тагын кистең, тагын ялгадың, тектең ди.

Сөйләшеп китсәң, әллә ниләр бар икән. Бервакыт хастаханәгә кислота эчеп үңәчен, ашказанын яндырган 30 яшьлек ир-атны китерәләр. Ашый да, эчә дә алмый, ярым үлеккә әйләнгән.Кемнәргәдер кирәге дә сизелми, елап йөрүчеләре дә юк. Менә аңа да операция ясарга Р. Таҗиев үзе алына. 7 сәгать ясый. Эчәктән үңәч тегеп куя. Үз эчәгеләреннән ашказаны ясый һәм теге бичара чын кеше булып аякка баса.




Ай-һай авыр, авыр икән хирург булып

эшләү. Анның әле үзенең дә йөрәге гел чыгымчылап тора. Ул инде, күпме сырхауның гомерен озайткан кеше, ике абыйсыз, ике апасыз калырга өлгергән. Шул инде – йөрәк чире. Рифкат абыйның үзенә дә операция өстәленә ятарга туры килгән. Аңа операцияне Мәскәүдә Ринат Акчурин үзе ясый. Бер ай дигәндә, ул терелеп эшенә чыга, тагын операция өстәле янына баса.

Урыс халкында, икенче тавышы ачылган, дигән бер гыйбарә бар. Чү, бу бит Әлфия Афзаловага кагыла түгелме соң? Ләкин безнең, икенче яшьлеге башланган, дигән үз гыйбарәбез дә бар. Бу сүзләр халык җырчысы Әлфия Афзаловага да, халык хирургы, профессор Рифкат Таҗиевка да турыдан-туры кагыла. Әйе, әйе, мин ялгыш әйтмәдем, - халык хирургы. Түрәләрне, байларны дәвалаучылар табылыр ул. Ә гади халыкны?.. Әлфияләребез гади халыкның җанын-рухын дәваласа, Рифкат Таҗи кебекләребез гади халыкны сортларга аермый гына тәнен-җанын дәвалый.

**Автордан:**

* Рабит Батулланың “Әлфия Афзалова” дигән китабында хирург Рифкать Таҗиев исеме дүрт урында макталып, рәхмәтләр юллап искә алына.

...Әлфия апаның тамагына операция ясадылар. Бу эшне атаклы хирург Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев башкарды. Аллага шөкер, табиблар вакытында өлгерде. Әлфия апа бик тиз савыга, тавышы ачыла башлады.(24 бит)

... Яхшы врачлар дәвалады мине. Рифкать Таҗиев миңа операция ясады. Алтын куллы врач! Рәхмәт! (42 бит)

... У меня голос пропал. Мне долго не говорили правду, но когда привезли в онкологическую больницу, я сразу все поняла… Операция по удалению опухоли прошла успешно. Я и не сомневалась в этом, потому что профессор Рифкать Тазиев – профессионал! А на профессионалов у меня нюх. Я как его увидела, сразу передумала ехать лечиться во Францию. После операции голос ко мне вернулся.(186 стр.)

... Батулла белән сөйләшкәннән соң, Әлфия апа йокымсырап китә һәм бик матур төш күрә. Ап-ак атка атланган егет Әлфия апаны алып китә. Дус-ишләре шикләнәләр, үзе исә: “ Тереләм”,- ди. Рифкать Таҗиевны ул елмаеп кабул итә.

Шулай булып чыга да. Рифкать Минһаҗ улы аз гына да шикләнми дә, икеләнми дә, данына күләгә төшәр дип тә уйламый. Башта Әлфия апаның тавышы кайта, аннан үзе терелеп аякка баса. (204 бит)

Казанский медицинский журнал, 2013. Выпуск 3, Страница 431-432

## Профессору Рифкату Мингазовичу Тазиеву— 70 лет.



С 1969 по 1971 гг. обучался в клинической ординатуре на кафедре хирургии и онкологии Казанского ГИДУВа. В эти годы он сформировался как высококвалифицированный хирург, владеющий методиками хирургического лечения практически всех локализаций злокачественных новообразований. Эрудиция и высокий профессионализм Р.М. Тазиева способствовали назначению его на должность заведующего отделением абдоминальной, а затем торакальной онкологии в Республиканском онкологическом диспансере. В 1981 г. Р.М. Тазиев был избран на должность ассистента кафедры хирургии и онкологии Казанского ГИДУВа, базирующейся на базе диспансера.

В 1983 г. Рифкат Мингазович успешно защитил кандидатскую диссертацию на тему «Спленопанкреатогастрэктомия в хирургии рака желудка». В 1986 г. был избран на должность доцента кафедры хирургии и онкологии Казанского ГИДУВа.

С 1990 по 1993 гг. Р.М. Тазиев исполнял обязанности заведующего кафедрой, а в 1993 г. был избран на должность заведующего этой кафедрой.

Многие годы Р.М. Тазиев углублённо занимается вопросами хирургического лечения рака пищевода и кардиоэзофагеальной области. По результатам этих исследований в 1997 г. в Российском онкологическом научном центре им. Н.Н. Блохина РАМН Р.М. Тазиев успешно защищает докторскую диссертацию на тему «Одномоментные операции в хирургическом лечении рака пищевода и кардиоэзофагеальной области».

Профессор Р.М. Тазиев опубликовал около 120 научных работ, посвящённых актуальным вопросам онкологической хирургии. Под его руководством и при научной консультации выполнены две докторские и пять кандидатских диссертаций. Он многократно выступает с докладами на научных конференциях и съездах, широко внедряет результаты научных разработок в практическое здравоохранение.

В 1998 г. избран членом-корреспондентом Петровской академии наук и искусств.

В течение 6 лет профессор Р.М. Тазиев возглавлял правление научного общества онкологов Республики Татарстан. За эти годы значительно активизировалась деятельность общества, проводились заседания совместно с научными обществами других специалистов: хирургов, эндокринологов, акушеров-гинекологов и др.

Профессор Р.М. Тазиев — член редакционного совета «Казанского медицинского журнала».

Рифкат Мингазович — высококвалифицированный хирург-онколог, выполняет все виды оперативных вмешательств на органах грудной и брюшной полостей. Большое внимание уделяет разработке и совершенствованию методик оперативных вмешательств при злокачественных новообразованиях. Имеет авторское свидетельство на изобретение нового способа дистальной резекции поджелудочной железы при комбинированных операциях по поводу рака желудка.

Профессор Р.М. Тазиев — заслуженный врач Республики Татарстан (1995), заслуженный деятель науки Республики Татарстан (2004), лауреат Государственной премии Республики Татарстан (2011). На V Съезде онкологов России был награждён почётной медалью. В 2006 г. награждён почётной грамотой Министерства здравоохранения и социального развития Российской Федерации. В 2010 г. награждён медалью Ассоциации онкологов России «За преданность профессии». В декабре 2012 г. удостоен звания «Почётный гражданин г. Менделеевска».

Профессор Р.М. Тазиев осуществляет общее методическое руководство лечебно-профилактической работой в клиническом онкологическом диспансере МЗ РТ, консультирует больных в лечебно-профилактических учреждениях г. Казани и Республики Татарстан.

Лекции и семинарские занятия Рифката Мингазовича всегда получают высокую оценку врачей-курсантов.

Трудолюбие, целеустремленность в достижении поставленной цели, высокая хирургическая техника, доброжелательное отношение к коллегам и пациентам, требовательность к себе и личная скромность Р.М. Тазиева служат примером для молодых хирургов. Профессор Р.М. Тазиев пользуется заслуженным авторитетом среди сотрудников академии, клинической базы кафедры, врачей-курсантов и больных.

*Сотрудники кафедры онкологии и хирургии ГОУ ДПО КГМА, врачи Республиканского клинического онкологического диспансера МЗ РТ,*
*друзья и коллеги сердечно поздравляют юбиляра, желают ему крепкого здоровья и дальнейших творческих успехов.*

*Редакция «Казанского медицинского журнала» присоединяется к этим поздравлениям.*

**Роза Булатова.**
**03.05.2013 Менделеев яналыклары, №33**

## Олы данга ирешеп тә, кече булып калганда…



Шушы көннәрдә Татарстан Республикасының атказанган табибы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, Халыкара фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, ТР Дәүләт премиясе лауреаты, медицина фәннәре докторы, КДМАның онкология һәм хирургия кафедрасы профессоры Рифкат Таҗиевка 70 яшь тулды.

Р.Таҗиев республикада гына түгел, аннан

читтә дә танылган табиб-хирург. Шул ук вакытта үтә дә тыйнак. Шагыйрь Ренат Харисның мондый юллары Рифкат Минһаҗ улы турында язылган кебек:

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт –
Иле өчен, халкы өчен
Яшәгәндә җан атып.

Замананың авырлыгын
Җилкәсенә алганда,
Олы данга ирешеп тә
Кече булып калганда.

Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаган якташыбызның хезмәт биографиясе 1966 елда башлана. Р.Таҗиевны юллама буенча Чувашстанның Яльчик районы больницасына җибәрәләр.

– Ул вакытны әле дә хәтерлим, – дип искә ала табиб. – Эшли башлавымның өченче көнендә йөк машинасында бала тапкан хатынны китерделәр. Сабый фельдшер кулында, ә кендеге әле әнисеннән аерылмаган. Тикшерә торгач, бәләкәчнең корсак өлешендә кимчелек ачыкланды: тире һәм мускулы юк, бавырын һәм эчәклекләрне нечкә элпә генә каплап тора. Сабыйга катлаулы пластик операция ясадым. Өч елдан соң, Яльчиктан бөтенләй китәргә йөргәндә, кулына зур чәчәк бәйләме тоткан кызчык әнисе белән бергә миңа рәхмәт әйтергә килде.

Бүгенге көндә онкологик авырулар медицинада гына түгел, социаль проблема да булып тора. http://oncofact.info/statistika/ сайтыннан алынган статистик мәгълүматлар уйланырга мәҗбүр итә.

● Һәр елны Россиядә 500 меңгә якын онкоавыру ачыклана.

● Россиядә бер тәүлеккә 1500 гә якын кешегә рак диагнозы куела.

●Илебезнең онкология больницаларында яки бүлекләрендә 2,5 миллионнан артык пациент исәптә тора.




Рифкат Таҗиевның табиблык итү дәверендә ясаган операцияләре бихисап. Ә бит кешенең организмына карап, һәр операция үзенчәлекле, бер-берсен

кабатламый. Көтмәгәндә төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Мондый вакытта хирургның осталыгы, югалып калмавы сорала.

Рифкат Минһаҗевич төп эшчәнлеге белән беррәттән онкохирургиянең актуаль мәсьәләләренә багышланган 114 фәнни эш бастыра, фәнни конференцияләрдә, съездларда чыгышлар ясый.

“МедФармВестник Поволжья” басмасына (15.06.11) биргән әңгәмәсеннән:

– Үз эшегездә нәрсәгә омтыласыз?

– Әлбәттә, катлаулы хирургик операцияләрне бик күп башкарырга була, ләкин шеш азгын стадиядә икән – нәтиҗә уңышлы һәм имин булыр дигән гарантия юк. Шуңа күрә, онкологиядә төп максат – шешләрнең үсешен кисәтү, аларны иртә диагностикалау.

– Миңа Рифкат Минһаҗевичта дәваланырга туры килде, – ди хезмәт ветераны Хәлимә Солтанова. – Ул һәр пациентка препаратлар белән бергә күңел җылысын да бирә. Үтә дә тактлы, шәфкатьле, игелекле.

“Рифкат” исеменең аңлатмасы да – “игелекле”. Аның бу сыйфатларын коллегалары, пациентлар гына түгел, гаиләсе, авылдашлары да билгели.

Рифкат Минһаҗ улына “Менделеевскиның почетлы гражданины” исеме бирелү, юбилее алдыннан Бәзәкәдә бер урамны профессор Таҗиев исеме белән атау – аның фидакарьлеген, тырыш хезмәтен югары бәяләү.

Статья из газеты: Еженедельник "Аргументы и Факты" № 21 21/05/2013

Старейший онкохирург Татарстана дал интервью

## Рифкат Тазиев: «Большая проблема - сделать так, чтобы люди дорожили собственным здоровьем»

**- Рифкат Мингазович, вы один из основателей республиканского онкодиспансера, в 1972 г. возглавили абдоминальное отделение, затем торакальное, были довольно молоды…**

- Прошёл закалку в райбольнице в Чувашии, куда попал сразу после института без специальной подготовки по хирургии. Вместе с операционной медсестрой делали около 400 операций в год. Работа научила принимать самостоятельные решения, - советоваться там было не с кем. Хотя со стороны государства так поступать с людьми, с молодыми специалистами было, конечно, неправильно.

**- А сейчас разве не так?**

- Стало лучше: специалисты учатся почти девять лет, но даже после ординатуры и интернатуры к работе не допустят без спецподготовки. Но дефицит кадров в районах огромен. Программы по привлечению молодых специалистов есть, но работают не так, как хотелось бы. Ну что такое миллион рублей? На эти деньги сейчас и дом в деревне не купишь.

Но дело не только в этом, важно воспитывать в будущих врачах человеческое отношение к пациентам. Мы учились на примере старых товарищей, беседовали с больными у постели, в кабинете. И люди это ценили. К сожалению, сейчас ощущается дефицит общения врача с больными.

**- Не хватает времени?**

- Я стараюсь ежедневно с утра обходить больных, которых оперировал. Кто-то, наоборот, больше времени проводит в операционной. За рубежом хирург, который каждодневно оперирует, также участвует в выхаживании больных. В своей клинике сын Дебейки (выдающийся американский кардиохирург) с двумя старшими помощниками в день делает 18-20 операций, недельная норма для большого института в России. Врач, который приходит работать к нему, обеспечивается домом, обслугой, машиной. Чтобы человек на работе ни о чём не думал. Нам в этом плане сложнее - жизнь у нас неустроенная. Тем не менее во время операции обо всём забываешь, так как важнее пациента ничего нет.

**- Сейчас здравоохранение реформируется, зарплаты врачам поднимают...**

- Неизвестно, к чему в итоге приведут реформы. Видимо, должно пройти какое-то время, прежде чем мы почувствуем реальный результат. Раньше был такой приказ Минздрава: в течение 10 дней принять решение о лечении больного. Сейчас на обследования может уйти месяц – запись по компьютеру, очередь. Думаю, в будущем всё-таки система нормально заработает, и эти недостатки будут устранены.

**Осторожно: заграница!**

**- В здравоохранение, в том числе и в РТ, вкладывается масса средств. Но постоянно собирают деньги на лечение детей за границей…**

- Это ужасно! Такое отношение к своим людям, тем более к детям! Были раньше купеческие фамилии, известные своей благотворительностью. Например, Шамов построил больницу и подарил её Казани. А где сейчас меценаты? Думаю, даже одного процента денег, что оказываются в руках коррупционеров и взяточников, хватило бы на лечение всех детишек.

**- Семья Птицыных из Казани собирала на лечение сына 18 млн руб. У нас даже за такие деньги не могут помощь оказать?**

- Заграничные клиники берут узкой специализацией – медучреждения подбирают людей по уровню подготовки, таланту, и вырастают хирурги высочайшего класса. Важен сервис – пациент попадает в другую атмосферу, где чувствует, что он нужен врачу. А там это чувство создают, потому что 10% дохода одной только клиники в Германии поступает от россиян. Нередки и случаи гипердиагностики. Как-то известного нейрохирурга попросили проконсультировать группу больных с межпозвоночной грыжей, отобрав их для поездки в Израиль. Выяснилось, что из 15 человек, по его мнению, в операции нуждались только двое.

В техническом плане, надо признать, наши зарубежные коллеги по некоторым вещам впереди. К примеру, в израильской клинике после операции рака простаты на следующий день начинают ходить, у нас могут лежать неделями. Есть сферы, где мы ни в чем не уступаем, например, в хирургии рака пищевода или желудка, когда приходится иметь дело с запущенными случаями, а их у нас много. Мы во многом отстали в последние годы. Загубили трансплантологию, хотя она зарождалась именно у нас. Владимир Демихов - основоположник мировой трансплантологии - в 40-е гг. стал первым врачом, пересадившим сердце в эксперименте, пересаживал вторую голову собаке. Какая техника должна была быть! Сейчас это направление у нас развито слабо – из-за отсутствия нормальной законодательной базы. И такая ситуация во многих сферах. А медицина больна тем же, чем болеет общество.

**Общее дело**

**- Вы говорите – масса запущенных случаев. Получается, врачи воюют с итогом наплевательского отношения нас к своему здоровью?**

- Мы никогда своей жизни не жалели. И государство не щадило - по результатам войны на одного убитого немца приходится несколько убитых советских солдат. Жуков говорил: «Не жалейте солдат, русские бабы ещё нарожают». Здоровье перестало быть капиталом. Люди не задумываются о том, что это позволяет работать и нормально жить. Китайцы каждое утро становятся на зарядку - все улицы заполнены. Думаю, что наша проблема во многом связана с общим низким уровнем культуры, крахом системы ценностей в 1917 г., в 90-х. Наверное, должны пройти годы, чтобы люди восстановили душевное здоровье.

**- Может, самочувствие граждан – не только их личное дело, но и государственное?**

- Конечно, надо стимулировать людей к здоровому образу жизни. Взять хотя бы борьбу с курением - вроде бы ужесточили закон, но одно дело принимать законы, и другое – соблюдать. Контроля нет, поэтому как курили, так и будут курить, если ничего не изменится. Американцы поставили задачу снизить заболеваемость раком лёгких на 50% за счёт борьбы с курением и заставили людей бросить эту пагубную привычку! В 9 случаях из 10 рак лёгкого возникает в результате курения. Сколько наших людей можно было спасти, если бы они бросили сигарету! Нужно сделать так, чтобы люди дорожили здоровьем.

**- Что лично вам помогает сохранить жизненный тонус?**

- Не курю, не пью. Нравится физическая работа в деревне.Всю свою хирургическую карьеру я всегда сильно переживал за то, что происходит. Смерть пациента выбивала из колеи. Перенёс три инфаркта, есть проблемы со сном. Всё-таки у врача должен быть инстинкт самосохранения. Ведь ты нужен людям, а умирать с каждым ушедшим больным невозможно. Поэтому берегите себя, бережно относитесь друг к другу, будьте добрее. Это поможет сохранить здоровье и продлить жизнь.

**Комментарий в интернете к данной статье.**

*“Рифкат Мингазович, какой Вы умница!! Как мало в нашей стране таких врачей- душевных, участливых...Сейчас выпускаются детишки тех, кто может оплатить учение, а очень немногие из них хотят лечить...хотят все стать главврачами и т.п. Вы учились в Советское время- где были совершенно другие ценности, и поэтому Вам не безразлична участь Ваших пациентов. Но,конечно же, и воспитание играет огромную роль...оно было раньше на высоком уровне- без телевизоров и компьютеров..живое человеческое участие...А сейчас детишкам больным собирают с миру по нитке..чтоб отправить в*

*правильную страну на лечение..а государство не помогает и копейкой... Вы еще затронули тему о гос.запрете на курение...кто курил-так и будут курить..НО...теперь будут штрафовать за курение в общественных местах- а это -везде, и , если раньше они выходили на лестничную площадку, то сейчас им это будет непозволительно и курить они будут ДОМА..при детях и всех домочадцах!!!! Неужели никто этого не понимает??? В заложниках у курильщика окажется вся семья....”*

**Мила Милова, 27.05.2013**

**Гөлнар Гарифуллина.**
**Казан, “Татар-информ”, 18 июнь,2013 ел**

## “Ел табибы-2013” мактаулы исеменә табиб-онколог Рәфкать Таҗиев лаек булды.



Барлык җиңүчеләргә һәм номинантларга статуэтка, диплом, планшет компьютерлар, республика Хөкүмәтеннән чит илдә стажировкага грантлар тапшырылды.

Бүген Казанда, Универсиада авылының Халыкара мәгълүмат үзәге залында үткәрелгән беренче чара кысаларында сәламәтлек саклау тармагы алдынгыларын хөрмәтләделәр. “Ел табибы – Ак чәчәкләр” VI юбилей конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасында РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Ольга Голодец, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, РФ Сәламәтлек һәм социаль үсеш министры урынбасары Татьяна Яковлева, ТР Сәламәтлек саклау министры Айрат Фәррахов, республиканың медицина җәмәгатьчелеге катнашты.

Табибларның халыкара ант сүзләрен игълан итү белән ачылган тантананы шоумен Михаил Волконадский һәм медицина фәннәре докторы, профессор, Беренче каналда “Здоровье”, “Жить здорово!”

тапшырулары җитәкчесе Елена Малышева алып барды. Иң элек залдагыларга “Ак чәчәкләр” республика премиясе тарихын чагылдырган фильм күрсәтелде, 2008 нче елдан башлап, һәр тантананың иң якты мизгелләре күз алдыннан узды. Бәйге үткәрелгән беренче елны ук тантананы алып барган Елена Малышева, фильмны карагач, иң беренче конкурс турындагы хатирәләре белән уртаклашты. “Ул елны хәтта төнге сәгать икедә тантанада катнашучыларга шалтыратып, сәхнәгә ничек чыгасылары турында сөйләшкән идек, чөнки беренче елны бик каушадык – шул хәтеремдә уелып калган”, - дип билгеләп үтте Елена Малышева. Ул Казанны бик яратуын һәм бирегә еш килүен, килгән саен уңай үзгәрешләргә тап булып, Казан белән соклануын ассызыклап үтте. Татарстанның, Россия төбәкләре арасында, искиткеч медицина хакимлек итүе буенча алгы сафта булуына басым ясады. Елена Малышева Татарстаннан үрнәк алып, иң яхшы табибларны чит илдә стажировка белән бүләкләүнең бөтенроссия дәрәҗәсендә гадәткә кертелү заруриятенә басым ясады.

“Бүген, йөрәк кушуы буенча гомерен шушы изге һөнәргә багышлаган затларны хөрмәтләү тантанасына җыелдык. Гаҗәеп фидакарь эшегез, тотрыклылыгыз, ныклы, чыдам булуыгыз өчен олы рәхмәт”, - дип ачып җибәрде Айрат Фәррахов тантананы.

“Ак чәчәкләр” конкурсында 5 номинациядә (“Сәламәтлек саклау өлкәсе легендасы” номинациясеннән тыш) 3 кандидатура тәкъдим ителгән. Алар һәммәсе дә тавыш бирүнең финал өлешенә кертелгән. Җиңүчеләрне ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет билгеләгән. Министрлыкның рәсми сайтында оештырылган интернет тавыш бирү дә җиңүчене сайлаганда мөһим роль уйнаган. Интернет челтәре аша номинантларга 30 меңнән артык тавыш бирелгән.

“Ел табибы” номинациясендә җиңү һәм ТР Президентыннан махсус бүләк – автомобиль хуҗасы булу бәхете Республика клиник онкологик диспансер табиб-онкологы Рәфкать Таҗиевка елмайды. Ул сәламәтлек саклау системасына 45 ел гомерен багышлаган шәхес. Аның турыдан-туры катнашында күкрәк һәм корсак өлкәләрендә шешләргә операция ясау ысуллары эшләнгән. Рәфкать әфәнде, 250 дән артык операция үткәреп, республикада үңәч рагы хиругиясенә зур саллы өлешен керткән. Мондый операцияләрне практикага кертеп җибәрү, элек операция ясау мөмкин булмаган авыруларга шифа өрергә мөмкинлек биргән. Атказанган табиб, профессор, абруйлы хирургның даны республикада гына таралып калмаган, аның исеме Татарстан

чикләреннән тыш та таныш. Рәфкать Таҗиевны Ольга Голодец һәм Рөстәм Миңнеханов бүләкләде.

РФ вице-премьеры чыгышында ассызыклап үткәнчә, бүген безгә Россия медицинасының элеккеге данын кире кайтарырга кирәк. “Бүген без шундый зур адымнар ясый алабыз ки, үзебезне дөньякүләм стандартларга тәңгәлләштереп карап түгел, ә үзебез үк шул стандартларны гамәлгә кертү буенча үрнәк була алабыз. Моның өчен күп укырга, тырышырга һәм үзебезгә карата таләпчән булырга кирәк. Без моны булдыруга сәләтле”, - дип белдерде ул һәм табибларга һәм аларның пациентларына сәламәтлек теләде.

*Ләйсән САБИРОВА.*
**“Халкым минем” гәҗите, №7(26) Июль, 2013ел.**

# Рәфкать Таҗиев:
# “Һәркем үз сәламәтлеген капитал дип санарга тиеш “.

Табиб турында сөйләгәндә, башка килгән беренче сыйфат – ул ышаныч. Кечкенәдән бу исем сихри мәгънә белән баетыла. Менә ак халатлы кеше сине кулыңнан тота. Инде аның куллары җылысыннан гына да шифа, дәва алгандай буласың. Бу кеше янында тыныч һәм рәхәт, чөнки син аңа зур өметләр баглыйсың, тормышыңны ышанып тапшырасың.

Кеше сәламәтлеген, ә кайчак гомерен дә саклап калу кебек олы йөкне тормыш мәгънәсе итеп сайлаган табибларны хөрмәтләү инде гадәткә әйләнде Татарстанда. Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы исемен йөрткән премия быел алтынчы тапкыр үз ияләрен тапты. Хирург-онколог Рәфкать Таҗиев 50 елга якын хезмәт юлында күпләргә ышаныч һәм өмет бүләк иткән кеше. Ул “Ел табибы” номинациясендә җиңүче итеп табылды. Ләкин пациентлары, хезмәттәшләре хөрмәтен һәм мәхәббәтен ул күптән яулаган инде. Рәфкать Мингазович белән аралашкан вакытта аның кабинет ишеге тыныч тормады. Минем алда гына да ничә табиб кереп, үзенең легендар кеше белән эшләвенә бәхетле булуы хакында әйтеп чыкты. Чын табибларга хас булганча иплəп, тыныч тавыш белән сөйләгән Рәфкать Таҗиев янында, чыннан да, һәр

авыру үзен ышанычлы хис итәдер. Безнең әңгәмә дә сизелми үтте.Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре докторы, профессор белән аның хезмәт юлы, һөнәр үзенчәлеге, сәламәт яшәү формуласы турында сөйләштек. Сезгә дә Рәфкать Мингазовичның уңай энергетикасын, яктылыгын җиткерә алырмын дип ышанам.

... Ә бит балачагында ул икенче юл белән китәргә уйлаган...

- Рәфкать Мингазович, табиб булу – балачак хыялымы, әллә бу һөнәрне сайлауга этәрүчеләр булдымы?

- Абыйның хатыны безнең авылда фельдшер булып эшли иде. (Рәфкать Таҗиев тумышы белән хәзерге Менделеевск, элеккеге Бондюг районы Бәзәкә вылыннан.) Ул минем дә табиб булуымны теләде. VII сыйныфны тәмамлагач, Алабуга медицина училищесына документлар тапшырдык. Ләкин мин анда уза алмадым. Ярый әле шулай килеп чыккан.Укырга кергән булсам, шунда гына фельдшер булып калыр идем. Гадәттә, мәктәпне тәмамлагач, кая барасы, кайда укырга керәсе дигән сорау туа. Мин дә башта бүтән юл белән китмәкче идем. Гаилә советында мин, бушлай белем бирә, ашата торган уку йортына керергә тиеш дигән карар кабул ителде, чөнки безне әллә ни тәэмин ителгән гаилә, дип әйтеп булмый иде. Дустым белән Чистай елга училищесына киттек. Анда судно механиклары әзерли иделәр. Документлар кабул итә торган механик миңа: “ Монда килеп ялгышкансыз. Билгеләрегез әйбәт, Казанга, Елга техникумына кереп карагыз. Барып чыкмаса, кайтырсыз – мин бер буш урын калдырып торам”, - диде. Кама буенда үскән малайларга теплоходларның нинди тәэсир иткәнен күз алдына китерәсездер?! Шуңа капитан буласы килә иде. Нәтиҗәдә, Казанга килеп, документлар тапшырдык, инде имтиханнар тапшырырга әзерләнә идек. Беркөнне урамда ялгыш кына Казанда читтән торып укып йөргән сыйныф җитәкчебезне очраттык. Ул: “Документларыңны кайсы уку йортына тапшырдың?” – дип сорады. Минем кая керергә җыенуымны белгәч: “Дөрес түгел бу. Безгә табиблар кирәк”, - дип, медицина институтына алып килде. Миңа кадәр безнең авылдан институтка бары бер кыз гына кергән иде. Казанга килеп, зур уку йортына керү юк иде инде ул вакытта. Мин беренчеләрдән булдым. Дәвалау факультетына кердем. Институтны тәмамлаганда, хирург булачагымны белә идем инде. Чөнки уку процессында ук хирургларга якынрак булырга тырыштым. Өченче курстан ашыгыч медицина ярдәменә йөрдем. Институтны тәмамлагач, мине тагын ике иптәшем белән распределение буенча Чуашстанга, Яльчик район үзәк хастаханәсенә җибәрделәр. Анда өч ел эшләдем. Башта хирург, аннары

баш табиб һәм хирург булдым. Бөтен хастаханәгә бер генә хирург булганга, эш күп, ял да юк иде. Табигатькә чыга калсаң, урынын төгәл әйтергә кирәк, ул-бу була калса, артыңнан килеп алалар. Еш кына төннәрен эшләргә туры килде. Катлаулы, авыр, ләкин үзем өчен файдалы мәктәп уздым. Районда эшләгәндә, елына 360-370 операция ясый идем. Акушер-гинекологлар белән дә хәл кискен булганга, бу юнәлештәге операцияләр дә ясарга туры килгәләде. 16 тапкыр бала тудыруда катнаштым. Сынган кул-аякларны төзәттем. Чуашстанда эшләгән вакытта, Казандагы табибларның белемнәрен камилләштерү институтында (ГИДУВ), хирургия-онкология кафедрасында ике айлык курслар уздым. Алыштырырга кеше булмаганга, башта җибәрми тордылар. Миңа хәтта министр алдына йә мине укырга җибәрәсез, йә мин хирург вазыйфасыннан баш тартам дигән шарт куярга туры килде. Нәтиҗәдә, җибәрделәр. Кафедра, андагы хирурглар эше бик ошады, мин дә аларга ошаганмын, күрәсең. Ординатурага чакырдылар. Беренче елын тимер юл хастаханәсендә уздым. Бу – алдынгы учреждение, анда авыруларга да эләгү җиңел түгел, чөнки биредә югары дәрәҗәле белгечләр эшли иде. Икенче елын шәһәр онкология диспансеры базасында үттем. 1971 нче елда Республика онкология диспансерына эшкә чакырдылар. Ул вакытта диспансер төзелеп бара иде. 1972 нче елга, медучреждение ачылганчыга кадәр, медицина хезмәткәрләрен әзерләү, җайланмалар урнаштыру белән шөгыльләндек. Диспансер ачылгач исә, баштан – абдоминаль, ике елдан соң торакаль онкология бүлеге мөдире булдым. Аннары безне, ике бүлек җитәкчесен, Михаил (Мойше) Сигал (танылган хирург-онколог, Казан онкологларының хирургия мәктәбенә нигез салган кеше) ГИДУВка, кафедрага ассистент итеп чакырды. Нәтиҗәдә, диспансерда да, кафедрада да эшләдем. Бүгенге көнгәчә торакаль бүлек кураторы булып торам. Хезмәт юлымның 42 елы шушы диспансер белән бәйләнгән. Кафедра һәм диспансерда бер үк вакытта эшләдем. Өч көн операция ясыйм, ике көн кафедрада укыту, фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнә идем. Тулаем алганда, 47 ел гомеремне хирургиягә багышладым.

- Елга портына укырга кергән булсагыз, Татарстан шундый хирургсыз калыр иде...

- Ул балалык кына булган инде. Ничек кирәк, шулай килеп чыкты. Мин бер дә үкенмим. Киресенчә, тиешле юнәлеш биргән кешеләргә рәхмәтлемен.

- Рәфкать Мингазович, Сезнең исемне республикада ашказаны яман шеше хирургиясе үсеше белән бәйлиләр. Сез күпләргә тормыш, яңа өметләр бүләк иткән кеше...

- Казанда онкология мәктәбенә нигезне профессорлар Юрий Ратнер һәм минем остазым Михаил Сигал салды. Һәм, әлбәттә, әлеге ике профессор җитәкләгән кафедралар хезмәткәрләре тырышлыгы белән күп көч куелды. Алар мине бик күп нәрсәгә өйрәтте. Хирургия – ул күмәк хезмәт. Аны бер кеше генә ясый алмый. Бер операциядә дә күпме кеше катнаша. Шуннан соң әле авыруга реанимациядә, аннары соң дәвалану алган бүлектә хезмәт күрсәтелә. Нindидер уңышларга ирешәбез икән, ул бер кеше хезмәте нәтиҗәсе генә түгел. Мин остазларыма, бергә эшләгән фикердәшләремә рәхмәтле. Бүген инде мин иң өлкән, яки иң карт (көлә – Л. С.) хирург. Һәр көн иртән табиблар өчен иртәнге конференцияләр уздырам.

Баштан ук безне барлык өлкәләрдә дә операция ясый алырлык итеп әзерләделәр. Элек баштан алып аякка кадәр операцияләр ясый идек. Аннары махсуслашу башланды, аерым бүлекләр барлыкка килде.



Мондый үзгәрешләр операция сыйфатына да яхшы яктан тәэсир итте, белгечләр әзерлеген күтәрде. Без ясаган операцияләрне бөтен җирдә дә ясамыйлар. Әйтик, пластик операция, сөт бизләре шешен дәвалауда тәҗрибәбез зур. Кайбер табиблар аерым юнәлешне үстерү җаваплылыгын үз өстенә ала, шуның нәтиҗәсендә тулаем онкохирургия үсеше тәэмин ителә.

Мин үземне күкрәк хирургиясе, аерым алганда, үңәч, үпкәләр, ашказаны, ашказаны асты бизе, эчәклек шешен дәвалауга багышладым, дип саныйм.

- Көненә ничә операция ясарга туры килә?

- Мин, нигездә, зур операцияләр ясыйм. Үңәчкә операция ясауга көне буе диярлек – 4-6 сәгать дәвам итә. Ашказаны асты шеше булганда, шулай ук күп вакыт сарыф ителә. Тиз эшләргә ярамый. Бик игътибарлы булырга кирәк. Аннан операция алдыннан аның күпме дәвам итәсен фаразлап, нинди буласын әйтеп булмый. Шеф

(Шәкертләре үз араларында Михаил Сигалны шулай дип йөртә – Л. С.) һәрвакыт: “Операция өстәле – ул спорт мәйданы түгел. Биредә тизлек өчен бүләк алмыйлар. Операция – ышанычлы, нәтиҗәсе уңай булырга тиеш. Авыру өзлегергә тиеш түгел”, - дип кисәтә иде. Шуны күздә тотып, әлеге максатка ирешергә кирәк.

Табибтан киңәш: Кеше сәламәтлегенең 70 проценты яшәү рәвешенә бәйле. Сәламәт яшәү – ул начар гадәтләр булмау, дөрес туклану, чиста экология, нәселдәнлек. Кеше сәламәтлеге 10 процентка гына медицинага бәйле дип санала. Һәркем үз сәламәтлеген борчусыз яшәргә ярдәм итә торган капитал дип санарга тиеш.

- Онкология белән авыручылар аерым игътибар таләп итә. Сез кешегә көч бирердәй сүзләрне ничек табасыз?

- Табиб һөнәре кешелек сыйфатлары булуны таләп итә. Ул белемле, киң күңелле, ихлас булырга, үз эшен намуслы башкарырга тиеш. Табиб нинди булырга тиеш дип сораганда, ул үз һөнәрен һәм кешеләрне яратырга тиеш, дип әйтер идем. Әгәр медицинаны яратмыйсың икән, бу өлкәгә килергә түгел. Үз һөнәрен яратмаган табиб авырулар өчен куркыныч. Онкологик авырулар белән эшләргә кыен. Ни дисәң дә, авыру кеше – бәхетсез , чөнки аның шундый кайгысы бар. Ул борчылганын күреп торабыз. Без дә шунда катнашабыз бит. Аларга операция ясыйбыз, аннан соң карап торабыз. Авыруның туганнары да бар бит әле. Алар белән дә операциягә кадәр, операциядән соң очрашып сөйләшергә кирәк. Үз кайгың булмаса да, авыр була. Бу эш табиб өчен дә психологик яктан авыр. Завод эшчесе көне буе станок артында эшләгәннән соң, өенә кайткач, аның турында уйламый да ала. Ә безнең белән авырулар турында уйлар өйгә ияреп кайта.

- Сез быел “Ел табибы” исемен алдыгыз. Ләкин пациентларыгыз, коллегаларыгыз ихтирамын Сез инде күптән яулаган кеше. Шулай да премия алу Сезнең өчен стимулмы, әллә өстәмә җаваплылыкмы?

- Бу премияне миңа бирү турында карар кылынганда, хезмәт юлым дәвамындагы башкарган эшне күздә тотканнардыр дип уйлыйм. Әлбәттә, мондый исем алуыма бик шатмын. Бу – олы дәрәҗә дә, коллегаларым һәм пациентларым ихтирамы билгесе дә. Премия алу белән миндә нидер үзгәрде дип әйтә алмыйм. Ничек эшләдем, алга таба да шулай эшләячәкмен. Бу миңа гына түгел, бөтен табибларга бирелгән бүләк. Мондый чара – безнең һөнәр ияләренә хөрмәт билгесе, ә табиблар мондый игътибарга мохтаҗ. Ул киләчәккә стимул булып тора.

# Йомгаклау.

Табиб профессиясе – җирдә иң гуманлы, иң кирәкле һөнәрләрнең берсе дидек. Чир уйламаган, көтмәгән вакытта тотып ала, чарасыз итә, куркуга сала, гомере кыл өстендә калган чакта кеше, ярдәм сорап, табиб алдына килә. Андый чакта сине җылы карашлы, ягымлы, ипле табиб каршы ала, файдалы киңәшләрен бирә, борчылырга урын калдырмыйча, барысын да тыныч кына, матур итеп аңлата, дәвалый, күңелне биләп алган шик-шөбһәле уйларны таратып җибәрә. Үз эшенең алыштыргысыз остасы булган шундый табиб кына – чын табиб. Авыруларның хөрмәте-рәхмәте чиксез зур аңа. Һәр табиб та шундый булса икән...

Әмма табибларның да төрлесе бар. Авырулар белән дорфа, илтифатсыз гына сөйләшүче, авыруның үзе белән түгел, ә бәлки, кадерле вакытны сарыф итеп, кәгазьләр генә актарып утыручылары да юк түгел шул. Андыйлар табиб Таҗиевның хезмәттәше, дусты, хөрмәт иткән кешесе, күренекле хирург, профессор Рәвил Шәймәрдановның газетага биргән интервьюсындагы сүзләрен ишетсенннәр иде. “ Табиб бик гадел булырга, кешеләрне яратырга тиеш. Әгәр табиб, аеруча хирург, үз авыруының чире белән “чирләмәсә”, аның газаплы сызлануларын җаны аша үткәрмәсә, ул - табиб түгел”,-ди ул. Бик дөрес сүзләр. Шөкер, авылдаш табибыбыз андыйлардан түгел.

Кулына табиб дипломы алганда биргән Гиппократ антына 50 ел тугры калып, Рифкать Минһаҗ улы хезмәт юлын туры, гадел, зур тырышлык һәм чиста намус белән үткән. Ул һәр пациентның сәламәтлеге өчен чын күңелдән борчылып, алар һәм коллегалары өчен мәрхәмәтлелек, итәгатьлелек, ихласлык идеалы, хезмәт сөючәнлек һәм тыйнаклык үрнәге булып тора. Аның эчке һәм тышкы дөньясы саф, матур, рухы бай һәм көчле. Затлы, зыялы була белеп, ул заман белән янәшә атлый. Тормыштан ямь һәм тәм табып, үзе кебек белемле, тырыш балалар үстереп, катлаулы да, мактаулы да эш- гамәлләре белән җирдә матур эз калдыра ул. Бу сүзләрне Рифкать Таҗиевның үз шигырь юллары да дәлилли:

Без яндырдык күктә ничә йолдыз,
Кешеләргә иттек игелек...
Аллаһ кушып, авыру алдында без,
Көннәр буе тордык иелеп.

Хәрәкәттә булды ми һәм зиһен,
Миһербанлык - шифа кулларда.
Кеше диеп үтте күпме еллар,
Күпме уйлар калган юлларда!

Әмма без дә адәм баласыдыр,
Бишегебез – гомер арбасы...
Әле күпме игелек эшлисе бар,
Әле күпме юлдан барасы...

Һәр төбәкнең танылган, мактаулы, горурланырлык кешеләре була.

Авылыбыздан Марсель Гыймазетдинов (1992 ел) һәм Рифкать Таҗиев (2003 ел) “Татар энциклопедиясе” нә кертелгән шәхесләребез.

Без – бондюглылар, бәзәкәлеләр - тарихларга кереп калырлык шушындый асыл затларыбыз белән чиксез горурланабыз .

Китапны төгәлләп, барлык авылдашлар, райондашлар, милләттәшләр исеменнән Рифкать Минһаҗ улы Таҗиевның үзенә озын гомер, ныклы сәламәтлек, күңел тынычлыгы, бары ак чәчәкләр кебек ак теләкләр генә телибез!

Олы җанлы, Олы йөрәкле,
Чиксез миһербанлы кешебез!
Сезнең алда баш иябез,
Сезгә Олы рәхмәт диябез!



# Гомернең бәхетле мизгелләре...
# (фото-ядъкарьләр)

## *Иң-иң газиз кешеләрем.*





**Минһаҗетдин Таҗиев гаиләсе**



**Рәхимә апа кызлары**
**Фәһимә һәм Хәлимә белән**



**Рәхимә апа улы Зиннур**



**Минһаҗетдин ага һәм аның 5 улы**



**Уллар, килен-оныклар белән**

*Бертуган Таҗиевлар*



Олы абый Зиннур



Мәэлүфә җиңги



Уллары Рәфис хатыны белән



**Бертуган Фәһимә апа ире Шәмсетдин белән.**



**Гәйнетдиновлар гаиләсе**





**Мулланур абый Таҗиев** **Аның хатыны Шәмсия апа**



**Мулланур абый гаиләсе**



**Хәлимә апа  һәм аның ире Фоат Маннановлар**






**Аларның уллары**





**Әнисә һәм Рәвил Шагиннар**



**Кызлары Миләүшә һәм аның кызы Энҗе**



**Бертуган Камил  һәм анын балалары**



**Кызы Наилә гаиләсе белән**




**Уллары Илшат һәм Руслан**



**Кече энекәш Шамил һәм аның гаиләсе**









**Туган йорттан китәсе килми...**




**Бергә чакта бик күңелле...**

## *Икетуган Таҗиевлар*



**Минһаҗ аганың бертуган энесе Фәттәхетдин хатыны Разия апа белән**



**Олы улы Шәйхенур**



**Икенче улы Хаҗинур**



**Аның улы Рифнур**



**Фәттәхетдин абыйның кызлары**



**Кече улы Рәфиснур**



**Минһаҗ аганың сугыштан кайтмаган энесе Фәссәхетдин абый**



**Улы Рафаил**



**Кызы Гөлфия**



**Өч бертуган**



**Икетуган энекәшләр**

## *Иң кадерлеләрем...*










## *Тугры дуслар.*






Alesia



**70 *еллык юбилей көннәре – 2013 ел, Казан.***



















***Туган көнегез белән сезне, Рифкат Мингазович,***
***без сезне бик яратабыз, хөрмәт итәбез!!!***

# Эчтәлек

Күңелдә йөрткән уй-теләк ........................................................ 3

Сүзем табиб турында............................................................... 3

Туган авыл................................................................................. 4

Өлкән Таҗиевлар...................................................................... 5

Кабатланмас балачак................................................................ 9

Күңелгә якын үсмерчак............................................................ 12

Студент еллары........................................................................ 13

Өем-йортым – гөлбакча........................................................... 16

Бәхетле кеше............................................................................. 20

Кояшым сүнгәндәй булды........................................................ 23

Кеше булган кешедә йөз кешенең эше бар............................ 25

Ранняя диагностика – спасательный круг.............................. 27

Татарстан Республикасы Президент Указы........................... 28

Ап-ак атларга атланып төшләргә кергән егет........................ 29

Профессору Р.М. Тазиеву- 70 лет.......................................... 34

Олы данга ирешеп тә, кеше булып калганда......................... 36

Большая проблема – сделать так, чтобы люди дорожили свом здоровьем……………………………………………… 38

Ел табибы – 2013……………………………………………… 42

Һәркем үз сәламетлеген капитал дип санарга тиеш................ 44

Йомгаклау................................................................................... 49

Материалларны компьютерда җыючы:
**Л.И. Мөхетдинова.**

Тышлыкның бизәлеше:
**Рекламная мастерская "Диз-Рекл",**
**Закиров М.Ф.**

Татарстан Республикасы,
Алабуга шәһәренең,
ООО "ЕлТИК" типографиясендә басылды.